

Фәрит Суфияров

# ЯЗМЫШ УРТАК



*Фәрит Суфияров*

# *ЯЗМЫШ УРТАК*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1998

ББК 84(Р-Тат)—5
С 88

Рәссамы *Виталий Булатов*

**Суфияров Фәрит**

Башкортостанда яшәп иҗат итүче шагыйрь Фәрит Суфияровның шигъри герое, кайда гына булса да, ил гаме белән яши. Тормышны ярату, туган җирне сагыну, аның гүзәллеген үзенчәлекле итеп күрә белү хас аңарга. Заманыбызның проблемалары да борчый аны, шул кыенлыклар алдында сыгылып төшмәскә чакыра ул безне.

ISBN 5—298—00750—3
© Татарстан китап нәшрияты, 1998



## РӘХМӘТ, ҖИРЕМ

Туган җирнең якты таңнары да,
Шунда тоям үлән йомшагын.
Җәйрәп яткан чиксез сәхрә-кырлар,
Миңа ачты иркен кочагын.

Чишмәләрнең көмеш моңы чыңлый,
Күгәрченнәр тынмый гөрләде.
И туган җир, ямьле, назлы да соң,
Хуш ис бөрки чәчкә, гөлләре.

Әтәчләрең иртән уяталар,
Тавыкларың җырын көйләде.
Урамыңда ак каеннар шаулап,
Серен уртаклашып сөйләде.

Кошлар кайтып ояларын корды,
Язмышларын сиңа бәйләде.
Басуларга сыймый иген уңа,
Куанычлы уңыш бәйрәме.

Рәхмәт, җирем, эчкән суларымны,
Икмәгемне синнән аламын.
Заман җилләренә күкрәк куеп,
Имән кебек үскән балаң мин.

## ЯЗМЫШ УРТАК

Ахры...
Йөргән юллар урау булды,
Үткәннәргә алып кайтмады.
Туган җирем, яшьлек күкрәүләрем,
Уйларымда һәрчак сакланды.

Авылдашлар, күңелем сезнең белән,
Ерак түгел безнең аралар.
Горур булып биек таулар гына,
Арабызда басып торалар.

Тормышыгыз шаулап чәчәк ата,
Олы шатлык һәрбер кешедә.
Кыңгыраулы пар атларда быел,
Кемнәр тагын килен төшерә?!

Күпләрегез яңа йорт өлгерткән,
Өй котларга кемдер җыена.
Юл уңае төшсә, мин дә кайтам,
Берегезнең бәбәй туена.

Максатыбыз безне очраштыра,
Юлларыбыз үтми бер читтән.
Инде кайда гына яшәсәк тә,
Язмыш уртак, язмыш бер икән.

## ЮЛАУЧЫГА ЮЛДАШ БУЛАМ

Тауга менсәм, тау буласым килә,
Моңы булам аккан чишмәнең.
Күккә карыйм тәрәзәмне ачып,
Йолдыз булып балкыйм кичләрен.

Мин камышы булам зәңгәр күлнең,
Дулкыннарын ярда кочармын.
Мин шоңкары булам кыяларның,
Офыклардан биек очармын.

Яз чәчәге умырзая булам,
Җиргә якты бизәк өстәрмен.
Кышы, язы, җәе, көзе булам,
Күзләр камашырлык төстә мин.

Кешеләрнең мин шатлыгы булам,
Күңел байлыгымны өләшәм.
Кардәшләрем сыман якын күрәм,
Сәлам биреп сезгә эндәшәм.

Юлаучыга юлдаш булып барам,
Маяк булам карлы юлларга.
Көмеш кыңгыраулар кебек чыңлап,
Җырым барсын ерак елларга.

## ВАКЫТ

Офык очларында яктылык бар,
Күк өстендә йөзә ак болыт.
Бәс җемелди каен чукларында,
Дөнья күренә күзгә ак булып.

Аклык белән шатлык очрашканнар,
Изге сәгать — кышның мизгеле.
Җәе-кышы, язы-көзе белән,
Вакыт тота көмеш тезгенне.

Еллар белән еллар алышына,
Җирдә кала тормыш мәңгелек.
Өметләрем, хыялларым кайчак,
Чәлпәрәмә килә бәрелеп.

Вакыт ала үз сагына кышны,
Зәһәр җилен, ачы буранын.
Җан ашкынып ташкыннарны көтә,
Елга ярын төшеп урадым.

Җил сызгырып, буран уйнаса да,
Вакыт җитсә, язлар соңламый.
Еракларга китеп күк читеннән,
Туар таңнар төнне сагалый.

## ИР ИТТЕ

Башны түбән игәнем юк,
Сер бирмәдем беркемгә.
Сагышларым, борчуларым,
Бетми калган бу көнгә.

Яшьлектәге хыялларым,
Артымнан һаман калмый.
Абынып егылган кеше
Үз хәлен үзе аңлый.

Күп нәрсәләргә төшендем,
Беләм суның агышын,
Әкияттәге малай төсле,
Дөнья белән таныштым.

Кабул итеп алам барын,
Шатлыгын, кайгыларын.
Чайкалып җиргә түгелде,
Эчкерсез тойгыларым.

Әзме өзгәләнде җаным,
Газабында тилмертте.
Сабырлатты тормыш мине,
Күпне күргән ир итте.

## СӘХРӘЛӘРГӘ ЧЫГАМ

Шау чәчәкле чагы болыннарның,
Басуларда иген өлгерә.
Елга ярларында чыңлап тора,
Су өстеннән дулкын йөгерә.

Кояш карый көлеп, назлый җирне,
Агач яфракларын алкышлый.
Күз күреме җитмәс киңлекләре,
Күк белән җир бергә тоташмый.

Иртәнге нур балкый тирә-юньдә,
Бар табигать шартын китергән.
Үзәннәрдә изрәп яткан томан,
Ак пәрдәсен инде күтәргән.

Кошлар тавышы керә колагыма,
Илаһи моң нинди кодрәтле!
Сәхрәләрнең шушы ямьле чагы,
Күңел кылларымны тирбәтте.

Күкләремә ашам канатланып,
Очып кунам күксел кыяга.
Уфтанмадым туган туфрагыма,
Узмады бит гомер заяга.

Урап йөрим сукмакларым буйлап,
Шатлыклардан йөрәк очына.
Горурланам басуларга карап,
Арышларым серкә очыра,
Офыкларым киңрәк ачыла.

## ТОЛ ХАТЫН МОНОЛОГЫ

Авыздагы канлы төкрекне дә
Күрсәтмәдем якын кешемә.
Күмерләргә әйләнсә дә йөрәк,
Сөйләп булмый барын кешегә.

Тол хатынның хәле кемгә кирәк?
Бар газабын ялгыз кичерә.
Гайбәтчеләр юкка рәнҗетәләр,
Нәсел-нәсәбеңне тикшерә.

Җаным горур, күңел китек тә соң,
Сер бирмәдем барбер ятларга.
Төшкә керә күңел тарткан кешем,
Туй атлары килми капкага.

Сөеләсем, бик сөясем килә,
Ялгызлыктан җаным өшегән.
Арттан йөрде күп егетләр элек,
Горурлыкның хәлен төшенәм.

Исерек ирләр килә ишегемә,
Гарьләндерә шундый төннәрдә.
Башларымны куяр урын тапмыйм,
Кайнар яшем тама мендәргә.

И йөрәгем, кимсетүгә түздең,
Олы бәхетләргә кызасың.
Саф мәхәббәт көтәм. Парлашып бер
Урамнардан килә узасым.

## БӨТЕН БАЙЛЫГЫМ

Биләүләргә, әни, төргәнсең син,
Назларыңны миңа биргәнсең.
Кояш кебек балкып елмайгансың,
Кайнар сулышыңны өргәнсең.

Алтын канатлы бул, күз нурым дип,
Иртә-кичен бәхет теләдең.
Отып алдым бишек җырларыңны,
Синең телең белән телләндем.

Күккә, айга, ерак йолдызларга,
Кулларымны сузып эндәштем.
Күңелемә минем моң салгансың,
Сандугачлар белән серләштем.

Тел ачкычын мирас итеп бирдең,
Юмарт булуыңны яраттым.
Телем белән таптым дошманымны,
Ә кайчакта дусны югалттым.

Сөенсәм дә үзем, көенсәм дә,
Эч пошырган уйдан айныдым.
Халкымның ул бетмәс хәзинәсе,
Туган телем минем байлыгым.

## ОРАН САЛАМ

Күп сөйлисең, чамаларны белми,
Шуңа, энем, телдән табасың.
Дустан дошманыңны аера бел,
Ятлар тозагына кабарсың.

Заманалар авыр, хәтәр чакта,
Күпләр үз өненә бикләнә,
Имансызлар, фахишәләр белән,
Күр, дөньялар ничек чүпләнә.

Борын тарткан яшел үлән сыман,
Җир өстенә калка вәхшилек.
Бабайларның матур йолаларын,
Беркем белми, кая яшердек.

Яңа гасыр капкасына кердек,
Әдәп бетә, нәрсә кала соң?
Борчуларым бетми, оран салам,
Кемнәр мине дөрес аңлар соң?

## ЯТИМ КАЛГАН ТИРӘГЕМ

Таулар чүккән, чишмә суы кипкән,
Авыл киткән күптән күченеп.
Су буенда, болыннарда йөрдем,
Баштан төрле уйлар кичереп.

Йорт нигезләре дә калмаган бит,
Карт топольләр тора калтырап.
Камыш үскән тынчу су өстендә
Кояш нуры уйный ялтырап.

Агач башларында буш оялар,
Моңсулана иртә-кичләрен.
Туган якка кошлар кайтыр микән,
Әгәр белсә авыл күчкәнен.

Тынлык баскан бөтен тирә-юньне,
Агымсулар өнен югалткан.
Юксынуым, сагышларым арта,
Бернәрсә юк мине юаткан.

Тын сукмаклар буйлап озак йөрдем,
Якты хатирәләр яңарсын.
Бабайларым яткан зират тора,
Тирәнәйтеп күңел ярасын.

Авылымның нигез ташы да юк,
Карашымны шуңа төбәдем.
Язмышларга ниләр булды икән:
Сабырлыгын җуйды йөрәгем,
Ятим калган яшел тирәгем.

## ХӨСЕТЛЕ КЕШЕГӘ

Иманыңны сатып син яшәмә,
Ике килми гомер беркемгә.
Битлек киеп йөргән клоун син,
Ничә төскә кердең бер көндә.

Дусыңны да, дошманыңны да син,
Икесен дә бердәй сатасың.
Юлларыбыз төрле якка китсен,
Аллам бер үк синнән сакласын.

Намус кирәк, иман кирәк тә бит,
Холкың белән андый түгелсең.
Уңны, сулны аера белмәсәң дә,
Гел хөсетлек кылып йөрисең.

Тар күңелле, кара йөрәкле син,
Кешеләрдән һәрчак шикләндең.
Телең белән генә күп эш кылып,
Йолдызларны күктән чүпләдең.

Карашларың җанны өшетерлек,
Зәһәр бозларыңны чәчәсең.
Изге күкрәк сөтен имеп үстең,
Яхшы күңел белән яшә син!

## ӨЧ ТӘРӘЗӘЛЕ ЙОРТЫМ

Кечкенә йорт, өч тәрәзә бары,
Әни, мине шунда тапкансың.
Йөгерек еллар үтте, үсеп җиттем,
Мин дә кактым тормыш капкасын.

Тәрәзәмдә уйный көмеш нурлар,
Яңа көнне күреп шатланам.
Туган йортым, синдә сөенеп яшим,
Салкын кыштан мине сакладың.

Тәүдә чыктым атлап бусагамны,
Йомшак сукмак булды юл башым.
Якты иртә белән кошлар дәшә,
Күк өстеннән карый кояшым.

Юк, тоймадым кечкенә йорт итеп,
Күпме хатирәләр саклана.
Нигез ташын әти үзе салган,
Куаныч хәл, күңел сафлана.

Җәйләр яшеллеккә төрә җирне,
Көз китерә яфрак сарысын.
Кечкенә йорт, өч тәрәзә аша,
Күреп, белеп яшим барысын.

## ҖИР КҮРСӘТМИ ЯРАСЫН

Уйларымда диңгез тирәнлеге,
Күңелемдә басу киңлеге.
Йөрәгемнән ташкан хисләр җиргә,
Ләйсән яңгыр булып түгелде.

Күзләремдә яшьлек ялкыны бар,
Якты йолдыз булып кабына.
Сулышларым йомшак җилләр кебек,
Үлән битләренә кагыла.

Күкләреңдә күкрәүләрең булам,
Офыкларда мин дә яшьнәдем.
Кара кайгыларга кайгырамын,
Шатлыкларга сөенеп яшәдем.

Тынгысызлык җанны биләп алды,
Борчуларым керде каныма.
Оеп торган тыныч уйларыма
Заман җиле килеп кагыла.

Чиксезлекләр били күңелемне,
Тик белергә кирәк чамасын.
Җир шикелле сабыр булсаң икән,
Ул күрсәтми бер дә ярасын.

## ҖЫРЛЫ КАЗАН!

Тәүге килүем бу, Казан, сиңа,
Урамыңа кереп адаштым.
Этләр чинап каршылады мине,
Башта алар белән таныштым.

Арлы-бирле килә, гөрли халык,
Кемнең кемдә нинди эше бар.
Кара ташкын кебек тоташ ага,
Урам тулып йөри кешеләр.

Тукайларның шөһрәт алган җирен,
Эзләп килдем ерак авылдан.
Ак биләүдә яткан чагымда ук,
Алар моңы миңа кагылган.

Татар каны йөгерә тәнем буйлап,
Кыйбла ягым беләм: үзгәрмәс.
Җырлы-моңлы Казан, син бар чакта,
Күңел күгем мәңге күгәрмәс.

## ХАЛКЫМ КӨРӘШӘ

Тел хакында кызу бәхәс бара,
Һәр милләтнең моңа хакы бар.
Үз йоласын, динен яклау өчен,
Җанын фида кылган халкым бар.

Ата-баба бүләк иткән безгә,
Мирас булып калган телебез.
Кыйбла ягын һәркем таный белми,
Нигә шулай төрле икән без.

Без — табигать балалары, аңлыйм,
Юмартлыгын биргән кешегә.
Минем халкым тел ачкычы сорап,
Әрсезләнеп керми күршегә.

Төрле яктан миссионерлар килеп,
Динен, телен көчләп такканнар.
Көн күрсәтми, юл бирмәгән алар,
Вәхши җаннар нәрсә тапканнар.

Яу кырына баскан солдат кебек,
Бүген дә бит халкым көрәшә.
Милләтемә үч саклаган күпләр,
Теле матур, шуңа көнләшә.

## ТӨШТӘ КҮРӘМ

Туган якның чиксез киңлекләре,
Яшел үзәннәре, гөлләре.
Җырлап аккан чылтыр чишмәләре,
Гашыйк итәр әллә кемнәрне.

Күңел хәзинәсен саклап йөртәм,
Хисләр таша ургып тирәндә.
Иртән торып мин юксынып йөрим,
Туган җирне төштә күрәм дә.

Оялардан очып ерак киттек,
Туфрак тарта, җанны җирсетә.
Уйландыра, борчый, тынгы бирми,
Оҗмахларда җәннәт күрсәк тә.

Күбәләкләр булып очты микән,
Җаныбызның әллә яртысы.
Күктән төшә сыман кояшның да,
Туган якка күбрәк яртысы.

## СӨЮДӘ СЫНАЛГАНСЫҢ

Чәч толымың иңнәреңдә,
Сүтәсеңдер хәзер дә.
Яз кояшы кебек калган,
Көлгән чагың хәтердә.

Ул чагында горур идең,
Борчылуны белмәдең.
Нинди кыяфәткә кердең,
Ничә төргә төрләндең?

Күзеңдәге утлы ялкын
Балкып бер дөрләгәндер.
Яшьлек дәрте, кайнар хисләр,
Тынгылык бирмәгәндер.

Ашкындың да, җилкендең дә,
Барып чыктың чигенә.
Мәхәббәттә алданучы,
Түгел ләса син генә.

Ялгыз гомер кичерәсең,
Сөюдә сыналгансың.
Бәхет белән афәт янәш,
Адымлап санагансың.

Назлы гөлгә тиз кагыла,
Иртә кырау тигәндер.
Язмышыңнан качалмыйсың,
Канатларың көйгәндер.

## КОШЛАР ДА СИНЕ САГЫНА

*Солтан Габәши кабере янында уйлану.*

Зират эчен яшел үлән баскан,
Киртә белән аны ураткан.
Каеннарның җилдә шаулаганы
Ишетелеп тора eрактан.

Түтәл кебек тезелеп киткән кабер,
Монда үскән гөле-чәчәге.
Заманында бу кешеләр нинди
Язмыш колы булып яшәде.

Күз нурымны түгеп карап йөрдем,
Арта монда кеше кадере.
Барысының уртасында күрдем,
Габәшинең тора кабере.

Яшен ташын күргән төсле тойдым,
Тез буыным кинәт калтырый.
Керфек очындагы яшь шикелле,
Үләндәге чыклар ялтырый.

Тирәкләрдә сандугачлар сайрый,
Тап булдым мин шундый чагыңа.
Җырчы кошлар хәтта, кешеләр күк,
Юксыныплар сине сагына.

## СЕРЛӘРЕМӘ, ӘНИ, КЕРДЕҢ

Кайтам дисәм, кайталмыйча калам,
Төрле хәлләр була, әнием.
Мин әйткәнчә генә килеп чыкмый,
Йөрәк белән сызып әрнием.

Ерак киттем, син озатып калдың,
Фатихаңны биреп юлыма.
Буш чемодан тотып көтмәгәндә,
Кайткан чаклар булды яныңа.

Кылган эшне, хәерлегә юрап,
Авыр минутымда юаттың.
Күрсәтмәдең яшьле күзләреңне,
Шәл читеңне генә чылаттың.

Газапларга салдым, әни, сине,
Утларымда, күрәм, янасың.
Докторлар күк үзең белеп кенә,
Күңел яраларын ябасың.

Серләремне, әни, уртаклаштың,
Болытлардан күгем ачыла.
Бу юлы да син якларсың, әни,
Кыргый җаннар миннән үч ала.

## БЕРЕНЧЕ КАР

Иртән торып тәрәзәмә карыйм,
Басуларның күренә бар төше.
Синең күз карашың кебек якты,
Ак күбәләк булып кар төште.

Кара җирне мамык карлар яба,
Йөгереп чыкты уйлар аклыкка.
Бәхетемә кызыл киртә салма,
Каршы килмә минем шатлыкка.

Ак моңнарга күмә тирә-юньне,
Төренеп кала дөнья биләүгә.
Табигатьнең матурлыгын күреп,
Сокланмыйча калмый берәү дә.

Энҗе бөртекләрен сибеп кырга,
Өметемне кабат терелттең.
Аклыгын да, шатлыгын да бергә,
Күңелемдә саклап йөреттем.

Керфек очларына килеп куна,
Күбәләк кар оча кырларга.
Ул үзенә матур чәчкә сайлый,
Гөлләр эзли кебек кунарга.

## ЮКСЫНУЫМ БЕТМИ

Сизмичә дә, белмичә дә калдым,
Уртасында хәтәр давылның.
Йомгак кебек сүтеп юлларымны,
Синнән алып китте авылым.

Бик күрәсе килгән чаклар була,
Җирсүләргә юктыр чаралар.
Куллар талыр, кош канаты итсәм,
Очып үтмәс ерак аралар.

Сагындыра болын сукмаклары,
Серләремне кемгә сөйләргә?
Пакусларны тезеп печән чаптым,
Изү ачтым эссе челләгә.

Юксынуым бетәр әле дисәм,
Еш керәсең авыл төшемә.
Ямьнәреңне күрми чит җирләрдә,
Югалтуны йөрәк төшенә.

## ГАРМУН ТАВЫШЛАРЫН ИШЕТСӘМ

Гармун тавышларын ишетсәм дә,
Тынычлана алмыйм чак кына.
Егет чагым гармун тотып әллә
Урамнарга мине чакыра.

Үзем уйнап йөргән гармунымны,
Күптән бирдем яшьләр кулына.
Эстафета булып калсын иде,
Тапшырырлар килер буынга.

Җырдан, моңнан аерылуы авыр,
Аерылсам да анам сөтеннән.
Күпме моңнар, күпме җырлар белән,
Гомер йомгаклары сүтелгән.

Минем яшьлек кайда күкрәп йөри,
Яфрак яра кайсы җирләрдә.
Тәрәзәмне тутырып ачып куям,
Туган яктан искән җилләргә.

Сагышларны, кайнар хисләремне,
Искән җилләргә мин таратам.
Узган яшьлек бер моңлы җыр булып,
Ишетелә кебек еРактан.

## ДУС ТА, ЮЛДАШ ТА СИН

*Г. Тукайга багышлап*

Яланаяк йөргән сукмакларым,
Малай чагым миннән еракта.
Бишегемдә чыңлап Тукай җыры,
Гомерлеккә калды колакта.

Гимн булып яңгырады җыры,
Мин битараф түгел гаменә.
Чигә чәчләремә ак төшсә дә,
Табынамын, димәк, әле дә.

Борчуларым шик астына куя,
Йөрәк эзли тизрәк дәвасын.
Ташкыннарга тиңлим җырларыңны,
Күңел сагышларын юасың.

Көр ишетелә илдә шагыйрь таушы,
Мирас итеп еллар саклаган.
Кайнар хисле, нечкә күңеллесең,
Шундый кешеләргә сокланам.

Йөргән юлда, озын сукмакларда,
Очрашмасак та гел бергә.
Якын дус та, юлдаш та син, Тукай,
Җырың белән яшим гомергә.

## ЧУАР ЗАМАНА

Чуар заманага килеп җиттек,
Гафләт баса, күрмим кызыкны.
Сәүдәгәрләр, коммерсантлар бергә,
Йөгереп узды алгы сызыкны.

Аптырадым мондый хәлне күреп,
Сискәндерде, кинәт айныдым.
Максатлар да төрле, уртаклык юк,
Ике якка юллар аерылды.

Спекулянт халкы базар сөя,
Сата-ала, юллый төшемен.
Кемнең кем икәнен белеп була,
Шөгыленә карап кешенең.

Юлны тапмый йөргән ерткыч кебек,
Бәргәләнә күпләр, сугыла.
Кая барганын да сизми кала,
Һаман ярга таба чигенә.

Аренага чыга минәүшикләр,
Исәп тотып алыш-бирешкә.
Харам малга кыза, алдый алар,
Берсе дә бит түгел фәрештә.

## АПРЕЛЬ ТАҢЫ

Җиләс иртәләре апрельнең,
Агач бөреләре ярыла.
Ярсый-ярсый ага кар сулары,
Елгаларның менә ярына.

Миңа тансык бу фасылы елның,
Бозлар агып сулар ташуы.
Җирнең гамен төсмерлимен инде,
Колагымда кала шау-шуы.

Якты нурлар тулды күзләремә,
Көзгеләргә карыйм мин иртән.
Назлар бүләк итеп таң атуын
Йөрәгемдә саклап йөретәм.

Апрель таңы сөю алып килде,
Җирнең артты якты бизәге.
Яшел үлән борын төрткән җиргә,
Күксел таулар кулын изәде.

Табигатьнең гүзәллеге бетмәс,
Бар төсләре балкый — өр-яңа.
Ямең арта, көчең сокландыра,
Ташу булып килдең дәрьяга.

## КҮРӘСЕМ ДӘ, БЕЛӘСЕМ ДӘ КИЛӘ

Мин тауларның биегенә менәм,
Дәрьяларның сайлыйм тирәнен.
Тирәнлеккә, биеклеккә гашыйк,
Әйдәләп гел тибә йөрәгем.

Зәһәр салкыннарда калганым бар,
Кайнар комын капшыйм чүлләрнең.
Ләззәт алып бик сөясем килә,
Бу дөньяның иң бер чибәрен.

Таң нурлары йөзләремә төшә,
Якты учак булып дөрләсен.
Иңнәремдә канат үстерәмен,
Күк юлларын килә күрәсем.

Теләк теләп, өмет баглыймын мин,
Максатыма барам иң элек.
Күпме эшләр көтә, кулым җитми,
Вакыт кыска, булмый өлгереп.

Күп күрәсем, күп беләсем килә,
Диңгез кичәм, илләр гизәмен.
Ил картлары кебек олы хөрмәт,
Әдәп барын җанда сизәмен.

## НИНДИ ҖИЛЛӘР ИСӘР

Төрле еллар, төрле чорлар булган,
Җилләр искән төрле тарафтан.
Ябырылып килгән кара болыт,
Илгә шомлы хәбәр тараткан.

Ачы җилләр искән җан өшетеп,
Ыңгырашу күмгән җир өстен.
Зинданнарга салып богаулаган,
Халыкларның тиран күбәсен.

Хәтерләрдән ничек юып ташлыйм,
Зилзиләләр купкан заманны.
Нинди җилләр алып килде икән,—
Яраларым кабат яңарды...

Иртәгәсен тагын җилләр исәр,
Нинди уйлар җанда яңарыр.
Ил язмышы күбрәк борчыганга,
Кара чәчем иртә агарыр.

## ҖЫР КАНАТЫ

Йон йомгагы итеп чорный гасыр,
Бер-бер артлы тезеп елларны,
Сугыш вәхшилеген татып шагыйрь,
Каны белән язган җырларны.

Йолкып ала уттан җыр канаты,
Суырып ала аны суыннан.
Ак күбәләк төсле Муса җаны,
Яу кырына килеп сугылган.

Утлы ядрә, кургаш өермәсе,
Кыршау сала аның юлына.
Күкләр, җирләр бергә тетрәгәндә,
Канга, яшькә килеп юлыга.

Горур башын түбән төшермәгән,
Ул басса да үлем каршына.
Җәллад тоткан, үз балтасын кайрап,
Үч алырга аннан ашыга.

Аяк-кулын тимер богау кыскан,
Шагыйрь кергән дошман өненә.
Җыр канаты тормыш упкынынннан,
Алып кайткан туган илемә.

## БҮӘ БУЙЛАРЫНДА ЙӨРИМ

Җаем уза Бүә буйларында,
Тугайлары аның җиләкле.
Кошлар сайрый яшел тирәкләрдә,
Ашкындырып минем йөрәкне.

Үзем генә йөргән сукмаклар бар,
Беркемгә дә әйтмим, сер итәм,
Күңелләрне һәрчак хушландырган,
Газиз җирем бары син икән.

Көннәр буе үз иркемдә калам,
Һичнәрсә юк мине борчыган.
Йөрәгемдә йөрткән аһ-зарларны,
Кошлар итеп барын очыртам.

Ничәмә төр монда өн-аваз бар,
Күктән көлеп кояш карады.
Сәламнәрен биреп баш өстеннән,
Акчарлаклар очып урады.

Сәхрәләргә чыксам, бушанамын,
Йөкләр төшә сыман иңемнән.
Бүә агышларын тыңлап торам,
Тирә-юнем моңга күмелгән.
Яр читенә таллар үрелгән.

## МИНЕ ТАБАРСЫҢ

Юксынганда сәхрәләргә чык син,
Булган сагышларың таралсын.
Киң кырларда тракторлар гөрли,
Буразнадан килсәң, табарсың.

Авыр уйларыңны читкә ташла,
Башка хисләр синдә яңарсын.
Чалгы янап болыннарны чабам,
Печән пакусыннан табарсың.

Йөргән сукмагымда гөлләр үскән,
Түшләреңә өзеп кадарсың.
Хезмәт дәрте белән яныып яшим,
Күзләремә кара, танырсың.

Айлы төндә урамнарга чыксаң,
Гармун тавышларын тыңларсың.
Юксынганда, борчылганда килеп,
Җырларымнан мине табарсың.

## ЕЛМАЕП-КӨЛЕП ЯШИМ

Сулар булып түгеләмен,
Утлар йотып дөрләдем.
Бу дөньяда яшәгәндә,
Бик күп төргә төрләндем.

Күзләремдә моңсулык бар,
Күңелдән сагыш ташты.
Шатлыклар көткән чагымда,
Кайгы болыты басты.

Хәтәр заманда туганмын,
Гомер тыныч узмады.
Давыллы көннәрне күреп,
И, йөрәгем сызлады.

Кошлар сыман талпынганда,
Канады канатларым.
Гомердә аянычлы хәл,
Күп тапкыр кабатланды.

Яңгырлар булып явамын,
Яшеннәр булып яшьним.
Бернәрсә булмаган төсле,
Елмаеп-көлеп яшим.

## ИЗГЕЛЕГЕН ТОЯМ

Күкрәк сөтен ризык итеп бирде,
Бишегемә килеп җырлады.
Биләүләргә төреп әни мине,
Ак юрганнар ябып зурлады.

Таң шикелле күз нурларын түгеп,
Сулышларын өреп җылытты.
Изге теләк, яхшы ният белән,
Кочагына алып яратты.

Күзләремдә йолдыз яктысы бар,
Син кабыздың, әни, очкынын.
Назларыңда йөздем аккош булып,
Дөнья имин, ирек ачылган.

Бишек җыры китми колагымнан,
Хәтер җуймый аны саклаган.
Ир уртасы булып җитсәм дә мин,
Һаман балачакка сокланам.

Иркәләдең, сөеп үстердең син,
Изгелегең телим тоярга.
Тормыш үрләренә алып мендең,
Бөркетләр дә куна кыяга.

## КӨЗГЕЛӘРГӘ КАРАП

Көзгеләрдә күрдем йөзләремне,
Иреннәрем кара көйгәнсез.
Күзләрем дә моңсуланып калган,
Бит очларым нишләп кибәсез?

Кара чәчләремә аклар төшкән,
Тирәнәйгән маңгай сырларым.
Ашкындырып торган хисләр сүнгән,
Кайда калды яшьлек елларым?

Мин төшендем: еллар узган саен,
Таулар кебек барыбер чүгәсең.
Якты төсләр, матур бизәкләр дә,
Шәфәкъ кебек сүнә күрәсең.

Көзгеләргә төшсә карашларым,
Вакыт узган саен шикләнәм.
Дәрья суы кибә, гөлләр шиңә,
Дөнья фани, гомер чикләнгән.

## ТОРМЫШ ЗАРЫ БЕТМИ

Тол хатыннар зарын ишетәмен,
Ятимнәрнең күрәм күз яшен.
Адәм балаларын язмыш кыйный,
Җәберенә барбер түзәсең.

Башны ташка орып буламыни,
Уйлар дәрьясына төшкәндә.
Ачлыгы да, сугыш афәте дә,
Читләмәде безне үскәндә.

Үги итеп кимсетүләр булды,
Шикләнделәр хәтта шәүләмә.
Усал ният белән кисәттеләр,
Күп сөйләшмә, диләр, шаулама.

Йөрәгемне чәнчү ала чеметеп,
Учларыма кысып тотамын.
Ятлар сөенмәсен, сер итәмен,
Кайгы-хәсрәтемне йотамын.

Кеше күңелендә тормыш зары,
Күрсәтә бит ачып — карасын.
Бу дөньяның колы итеп тота,
Бер кызганмый адәм баласын.

## КЕШЕ КҮҢЕЛЕ БУШАНСЫН

Ап-ак карлар булып явам,
Бар дөньяны агартам.
Бу тормышка ямьнәр өстим,
Якты төсләр таратам.

Җир өстенә бизәк өстим,
Яшел чирәмнәр булам.
Мин юмарт, изге күңелле,
Табигать, синең балаң.

Басу түрендә шаулаган,
Игеннәр булып үсәм.
Ерак офыклардан киләм,
Назлы җил булып исәм.

Елның төрле фасылы мин,
Язы, җәе, кышы булам.
Тирәкләрдә канат каккан,
Сайраган кошы булам.

Ай, кояш булып елмаям,
Җиһанны нурга төрәм.
Кеше күңеле бер бушансын,
Моңлы җыр булып керәм.

## БӘРӘКӘТЛЕ ҖИРЕМ

Җилкендерә җилләр курай уйнап,
Камышларны ярда биетә.
Күксел кыяларга гашыйк булып,
Бөркет канат кага биектә.

Дулкын кага елга ярын килеп,
Ташларына тиеп ярсыма.
Бодай башакларын тирбәлдерә,
Алтын төсе кергән басуга.

Чигү җебе төсле кояш нуры
Бизәкләде офык челтәрен.
Хыялыма каршы йөгереп барам,
Чыгалмадым аның чикләрен.

Тауларның бар бетмәс хәзинәсе,
Чишмәләрең саклый шифасын.
Назларыңны, ямьнәреңне күрдем,
Кызлар кебек, җирем, зифа син.

Бәрәкәтле туфрак, нигъмәте зур,
Ризыгымны синдә җыямын.
Сагышымны керле күлмәк итеп,
Аккан суларыңда юамын.

✿

## ЧИШМӘ ТАВЫШЛАРЫ

Чылтыр-чылтыр аккан чишмәләрнең,
Колагымнан китми тавышы.
Күңелемә бетмәс моңнар салды,
Әллә йөрәк шуңа сагышлы.

Иртә-кичен чишмә буйларына,
Төрле кошлар килеп сайрады.
Ташны ватып, тауны тишеп чыккан,
Ярсу сулар ярда чыңлады.

Монда ничә төрле моң-аваз бар,
Йөрәк аша барын кичерәм.
Ак кәгазьгә шигырь итеп язам,
Дәфтәр битләренә күчерәм.

Чит ярларга илтер чишмә моңын,
Мин ышанам аның көченә.
Җырлар-моңнар җирдә яңгырасын,
Яшәү ямьле булсын кешегә.

## ХӘТЕР КИТАБЫ

Мин актардым хәтер китабымны,
Узган вакытларга карадым.
Йөгереп кенә кайтып бала чакка,
Болыннарны чыгып урадым.

Дусларымны күреп, барлап чыктым,
Мәҗлесләрнең булдым түрендә.
Бер ваемсыз үткән шат көннәрем,
Кайгы болыты юк күгемдә.

Хәтер китабымны актарганда,
Мин тап булам шомлы елларга.
Кайгыларым кара шәлен сөйрәп
Чыгып баскан йөргән юлларга.

Ерак калган еллар кайтавазы,
Ялгыз калсам, килеп чаң кага.
Тетрәнә күңел кинәт кенә,
Диңгез дулкыныдай чайкала.

Хәтер китабына бар да сыйган,
Еллар саны узган гомердә...
Язмышыма ятлар сөенмәсен,
Зарланмадым шуңа мин бер дә.

## БАСУ ЮЛЛАРЫ

Хозурлыгы нинди җәй аеның,
Ләззәтенә туйган юк әле,
Якты таңнар, зәңгәр иртәләре,
Җәйрәп ята басу юллары.

Җилфер-җилфер арыш серкә очра,
Чык суында пешә җиләге.
Карап йөрим, озак урап йөрим,
Күз күреме җитмәс җирләрне.

Баш өстендә кояш балкып көлә,
Яшел бәрхет җирнең өсләре.
Тау астында чишмә җырлап ага,
Ул уята сихри көчләрне.

Кан тамыры төсле сузылган да,
Төрле якка юллар тарала.
Биеклеккә карап басып торам,
Бөркет кунган горур тауларга.

Үзәннәрдә яшел яфрак шавы,
Чәчкәләрдән хуш ис түгелә.
Талларына сайрар кошлар кунган,
Җиләс шәүлә ята төбендә.

Таулар канатына менеп баскач,
Күтәреләм мин да югары.
Җанга рәхәт, илаһи көч бирә,
Чакырып тора басу юллары.

## ТАШУ СУЛАР АГА

Елга ярларыннан ташып чыкты,
Ярсып ага язгы ташулар.
Үзәннәрне, су буйларын биләп,
Тынлыкларны куа шау-шулар.

Сулар ургый, бозлар актарыла,
Дулкыннар да чәчте күбеген.
Авыр тойгылардан аз булса да,
Бушанырга тели күңелем.

Әрнүемне, борчуларны барын,
Ташу суларына саламын.
Канатланып, күкрәп каршылаган,
Узган язларымны саныймын.

Кимсенүләр, вакланулар бетми,
Агып китсен күңел бозларым.
Заманасы нинди чуарланган,
Миңа җитми, тормыш, назларың.

Таулар булып дулкын килгән чакта,
Арта төсле бары ярсуым.
Җирдә булган бөтен хәсрәтләрне,
Алып китсен юып кар суың.

* * *

Их, дигәнче бер ел узып китте,
Ел өстенә еллар өстәлде.
Вакыт яңгырлары юып алды,
Күземдәге якты төсләрне.

Яфракларын койган агач сыман,
Ник, күңелем, тәмам бушандың?
Көч тә бетә, дәрт тә сүнә бара,
Еллар үткән саен ышандым.

Маңгаемда буразналар төсле,
Сырлар арта бер ел эчендә.
Табышым да, югалтуым да күп,
Мин җаваплы барсы өчен дә.

Сизелми дә кала еллар үтә,
Юллар илтә гомер көзенә,
Дуслар, бары сез аңларсыз мине,
Сары сагыш чыкты йөземә.

## ҖИР ЯМЕ

Кара, зәңгәр чатыр күгем,
Җирем — яшел бишегем.
Анадан тугач та күрдем,
Дөнья матур, юк шигем.

Ил картлары кебек тыйнак,
Чалмалы биек таулар.
Бәйрәм күлмәкләрен киеп,
Чукларын аскан таллар.

Дәрьяларым шаулый-гөрли,
Егетләр кебек ярсу.
Сары гәрәбә төсендә,
Күренә күзгә басу.

Кызлар кебек асыл булып,
Җиремдә үсә гөлләр.
Куанычы белән килә,
Миңа бу якты көннәр.

Таңнар, шәфәкъләр балкышы,
Нурга күмә кич-иртән.
Чишмәләрнең көмеш моңын,
Сәхрәләрдә ишетәм.

Күз камаша бизәкләрдән,
Көн-төн чигү чигәсең.
Яшь киленнәр кебек җирем,
Сокландырдың, чибәрсең.

## ЧИТ ҖИРЛӘРДӘ ГОМЕР ҮТӘ

Чит җирләрдә яшәп гомер үтте,
Туган якка юллар төшмәде,
Сукаларга җиккән җирән атым,
Төшләремә кереп кешнәде.

Иреннәрем кибә сусаганда,
Чишмәләрем чакырып чыңлады.
Гөлгә иртә тигән кырау кебек,
И, вакытсыз чәчем чалланды.

Туган яктан ерак китсәм дә мин,
Бәхетемне эзләп тапмадым.
Бик күп усаллыгын, явызлыгын
Көнчелеген күрдем ятларның.

Ташлар ваттым, карурманнар кистем,
Җиңел эшне сайлап алмадым.
Мең яшәтер төсле кыландыра,
Дөнья фанилыгын аңладым.

Яшәү — минем бөтен куанычым,
Белеп, күреп, сөйләп, аңлашып.
Яралы кош кебек бәргәләнеп,
Ялгыз башым йөрдем адашып.

## КАРЛАР КҮМГӘН ТУГАЙЛАРНЫ

Печән кибәннәрен карлар күмгән,
Көртләр баскан тугай юлларын.
Скрипка кыллары күк монда,
Өзелеп калган тургай җырлары.

Өн-аваз юк, тирә-юнем тыныч,
Тугайларны урап үткәндә,
Кошлар кайткан, бөреләнгән имеш,
Язны күреп таллар төшләнә.

Болын итәкләрен ябып йоклый,
Мамык юрганына төренеп.
Тирәк очларында ак мәрҗәннәр,
Юл читеннән тора күренеп.

Кар бөртеге кояш нурын җыйган,
Балкып кала баскан эзләрем.
Ак моңнарга күңел шашынасың,
Ак җәүһәргә гашыйк күзләрем.

## НИНДИ ХӘЛГӘ КАЛДЫК?

Гадел кеше булып яшәү авыр,
Гел әйтәсең, әни. Син хаклы.
Мошенниклар алыш-биреш итә,
Урлашалар күпләр бу чакны.

Бүре көтүедәй табыш эзли,
Хуҗа булган кемнәр дөньяга?
Илне талый, машинасын ала,
Биек йортлар сала өр-яңа.

И, кызганыч, сәер хәлгә калдык,
Шау-шу, бәхәсләрдән ялыктык.
Халык зарлы, ышанычы бетте,
Бөлгенлеккә тәмам юлыктык.

Күпләр хәзер хәер эстәп яши,
Вокзалларда, базар чатында.
Ә берәүләр кәеф-сафа кора,
Акча суза чибәр хатынга.

Уңга-сулга карыйм: бертөрле хәл,
Чыгарылган аның карары.
Әллә кылган гөнаһлары өчен,
Кешеләрне Алла каргады.

Кайда хаклык, кайда ялган бүген,
Төрле төсләр бергә бутала.
Кимсетүгә, рәнҗетүгә түзми,
Җан борчыла, җанны ут ала.

## ЯЛГЫЗЛЫК ХИСЕ ТОЯМ

Эчкән суның төмен тапмыйм,
Йокым качты күземнән.
Борчуларга төшкән мәлем,
Сагыш китми йөземнән.

Давылларга каршы торган,
Бер имән булсам икән.
Ваемсыз малай шикелле,
Ирсәеп йөрсәм икән.

Ни эшләргә дә белмимен,
Шөбһәләнәм, тынгы юк.
Тол калган хатыннар кебек,
Күңел нигәдер боек.

Газапланган сәгатемдә,
Үземә сорау куям.
Өметсезлек, моңсулык бар,
Ул килә миңа каян?

Адашкан юлаучы итеп,
Ялгызлык хисе тоям.
Горур имән күкрәгенә
Шуңа башымны куям.
Җанда ышаныч тоям.

## КАРЛАР ЯВА

Тау-тау булып каурый болыт йөзә,
Галәмнең бу изге сәгате.
Җир өсләрен ак биләүгә төрә,
Табигать ул нинди сәләтле.

Оеп кына ап-ак карлар ява,
Фәрештәләр канат җәйгәндер.
Кыш аеның аклыгына кызам,
Озак көттем аны нигәдер.

Учларыма җыям яуган карны,
Ак мәрҗәннәр төсле тоела.
Бөтен җанны, тәнне агартырдай,
Күк өстеннән йолдыз коела.

Ак бәхетләр алып килер төсле,
Чынга аша хыял бу көндә.
Тойгыларга, якты хисләремә,
Чик куялмас кебек беркем дә.

## КИЛӘЧӘККӘ КАРЫЙМ

Бездән соң да ямьле язлар килер,
Күкрәп явар җылы яңгырлар.
Иген кырларында тургай сайрар,
Ил өстендә җырлар яңгырар.

Киләчәккә барыр ара ерак,
Барып җитмәс җитез кошлар да.
Вакыт хөкемендә кала бар да,
Кабер өстендәге ташлар да.

Бу дөньяга кемнәр генә килми,
Якты көннең алып сәламен.
Язмыш төрле, вакыт ашыктыра,
Аңламыйча калам сәбәбен.

Киләчәкне күзаллыймын үзем,
Җәе озын, кышы кыскадыр.
Үсмер кызлар кебек хыялланам,
Хыялларым, ахры, бушкадыр.

Гомер озынлыгын еллар саный,
Кай якларга китеп өлгерде.
Малайлар күк, күңел исәпләшми,
Киләчәккә табан йөгерде.

## ПЕЧӘН ЧАПКАН ТУГАЕМ

Ат саклаган, печән чапкан,
Җиләк җыйган җирем син.
Гомерлек яшел тугаем,
Җырлап туймас җырым син.

Көмеш кебек җем-җем итеп,
Үләннәрдә чык балкый.
Җанга рәхәт, ләззәт табам,
Чәчкә исләре аңкый.

Сукмакларым онытмаган,
Йөргән эзем сакланган.
Җир авазы, кошлар моңы,
Хәтеремнән чыкмаган.

Яшеллеккә күмелгәнсең,
Сафлыгыңа табынам.
Ураү юллар аша килдем,
Сагыш хисе кагылган.

Күзаллыймын сукмакларны,
Табигать кочагында.
Очкыннар сибеп янсын бер,
Ут алсын учагыңда.

## СИН ЯШЬЛЕК ЯЗЫҢДА

Сиңа бары унҗиде яшь кенә,
Гомереңнең алтын мизгеле.
Дәрья суы кебек ага шаулап,
Сизелми дә вакыт тизлеге.

Йөзләреңдә нур балкышын күрәм,
Чәчләреңдә шомырт карасы.
Юлларымда сине очраттым да,
Тартып алдың минем карашны.

Яз чәчәге кебек нәфиссең син,
Назлар өчен җиргә тугансың.
Дәртләндердерең сихри көчең белән,
Минем күңелем сиңа табынсын.

Сөенечле булды йөргән юлым,
Могҗизаларга мин ышанам.
Урал бөркетедәй канат кагам,
Офыклардан биек оча алам.

Кабатланмас яшьлек язымда син,
Горур затсың — шулай кирәктер.
Гашыйк булып кара, кайнар хисләр,
Синең җаныңны да көйрәтер.

## ЕГЕТ БУЛУ КИРӘК

Егет чакта чаптар атның,
Кулда булды тезгене.
Хуҗа булдым әйткән сүзгә,
Сынатмадым үземне.

Гомер йомгагы кешенең,
Кайчак җиңел сүтелә.
Бер адымың харап итәр,
Бассаң, упкын читенә.

Егетлек, кыюлык кирәк,
Биек үргә менәргә.
Ут-суларны кичкән була,
Дөнья күргән ирләр дә.

Хәтәр заманага калгач,
Адымыңны санийсың.
Тормыш юлы адаштырмас,
Нинди юлны сайлыйсың?

Борчылырга урын да бар,
Уйсыз кеше сирәктер,
Авырлыклар килгән чакта
Егет булу кирәктер.

## МИНЕМ КҮҢЕЛ

Ап-ак карлар булып явам,
Дөньяларны агартам.
Бу тормышка ямьнәр өстим,
Якты төсләр таратам.

Җир өстенә шытып чыгам,
Яшел чирәмнәр булам.
Табигать, мин синең юмарт,
Изге күңелле балаң.

Басу түрендә шаулаган,
Игеннәр булып үсәм.
Зәңгәр офык читләреннән,
Назлы җил булып исәм.

Елның төрле фасылы мин,
Язы, җәе, кышы булам.
Тирәкләрдә канат каккан,
Сайраган кошы булам.

## ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ

Май кояшы балкый күк өстендә,
Нурга күмеп бөтен дөньяны.
Мәйдан тулы халык ташкынына
Оркестрлар марш уйнады.

Ветераннар килә әкрен атлап,
Тере чәчкә тотып бу көнне.
Күкрәкләре орден-медаль тулы,
Карашлары көләч, сөйкемле.

Җиңү көне, олы шатлыгыбыз,
Безнең йөзебездә чагыла.
Ватан күген бизи ал байраклар,
Тантаналы бәйрәм чагында.

Горурлану хисе мәңге сүнмәс,
Һәйкәлләрдә чәчкә бәйләме.
Дөнья балкый, илем салют бирә,
Бүген җирдә җиңү бәйрәме.

## УЗГАН ГОМЕР УЙЛАНДЫРА

Гомер узган саен уйландыра,
Шөбһәләнәм, күп чак шикләнәм.
Якты көнем төнгә алмашына,
Мин аңладым: бар да чикләнгән.

Матур бизәк тә бит төссезләнә,
Тузып бетә кигән кием дә.
Соңгы юлга адәм балаларын
Озаталар матәм көенә.

Җир назына күптән күнеккәнмен,
Бишегенә салып тирбәтә.
Тормыш ваклыгына күмелмичә,
Яшәү кадрен белү кирәк тә...

Йөз яшәргә йөрәк талпынасың,
Шик төшерә нинди күләгә.
Ике яшәмисең, гомер кыска
Күпме генә теләк теләмә.

Тәкъдиреңә каршы килалмыйсың,
Нәрсә кылсын адәм баласы?!
Тәңгә чыккан шеш шикелле сызлый,
Төзәлмәслек күңел ярасы.

## КӨТКӘН КӨНЕМ

Ак күлмәк киеп өстемә,
Көзгеләргә карадым.
Тансык миңа көткән көнем,
Чәчләремне тарадым.

Сирәк калган чәчләрем дә,
Маңгайга сыр сызылган.
Басу юлы кебек ята,
Төрле якка сузылган.

Бер ел вакыт үтте тагы,
Соңгы декабрь көне.
Бу хәл кабатлана торган,
Нишләсен күңел күнде.

Сүнгән учак кебек калды,
Көннәр, төннәр — вакытлар.
Көенечләр, сөенечләр,
Җанда булган ваклыклар.

Яңа ел көткән сәгатем,
Калам изге теләктә.
Ятим калган йорт шикелле
Юксыну бар йөрәктә.

## ГОРУРЛЫК ХИСЕН САКЛЫЙК

Озак вакытлар үткәрдек,
Йокыдан уяныйк.
Үзгәрешләр заманасы,
Бергәләп уйланыйк.

Халкыбызның яманатын,
Сатканнар бер дә юкка.
Кош оясы кебек тузып,
Сибелгән төрле якка.

Без тарихта эзле халык,
Ирек, хөрлек юллаек.
Язмышыбызга кол булып,
Күзебезне йоммаек.

Ата-ана телен белми,
Милләтен танымаган.
Маңкортлар күбәйде хәзер,
Җыр-моңга табынмаган.

Халыкның изге теләге,
Калыкты кинәт өскә.
Зәңгәр күзлектән карадык,
Бар дөньяны бер төстә.

Ориентирлап юлыбызны,
Еллар ишеген шакыйк.
Милли тойгылар уянсын,
Горурлык хисен саклыйк.

## МӘХӘББӘТЕҢ БАРЫН ТОЙДЫМ

Ялгыз иттең, мине ташлап киттең,
Шәльяулыгың калган онтылып.
Кулым белән йөрәгемне тоттым,
Кайгыларым калды йотылып.

Агы-күге күзгә күренмәде,
Кара болыт каплый күгемне.
Кайнар яшем дәрья суы булып,
Мендәр читләренә түгелде.

Дөнья куанычы миннән китте,
Шатлыгымны алдың үзеңә.
Киткән юлларыңа карап калдым,
Үзәкләрем генә өзелә.

Авыр сүз дә әйтеп рәнҗетмәдем,
Хәер, үзең теләп киткәнең.
Тормышымның очын син чуалттың,
Бу кайгыны һич тә көтмәдем.

Күз төбендә кайнар яшем кипте,
Ут-ялкыны миндә сүрелде.
Мәхәббәтнең чын икәнен белдем,
Хәзер тойдым татлы сөюне.

## ДАЛА

Күк белән җир тоташмаган,
Офыклар ерак киткән.
Безнең бабайлар төпләнеп,
Яшәгән монда күптән.

Чиксез дала киңлекләре,
Күз карашларын тарта.
Болыннар, басулар аша,
Бушанып юллар ята.

Дала йокымсырый төсле,
Вакытлар тыныч ага.
Чал кылганнар, зың-зың килеп,
Җилгә башларын кага.

Төрле яктан юллар килеп,
Йомгак кебек төйнәлгән.
Күктә көлеп кояш карый,
Якты караш төбәгән.

Таңнар, шәфәкъләр яктырып,
Күкләрен бизәп балкый.
Иркенлеген, чиксезлеген,
Дала гомергә саклый.

## ДУЛКЫН УЯТ

Елга өстен күксел бозлар төргән,
Көзләр килә монда соңламый.
Табигатьнең үз законы яши,
Кешеләрдән киңәш сорамый.

Тал-тирәкләр туй күлмәге кигән,
Бәскә каткан ап-ак чуклары.
Язны сагынып шаян дулкыннар да,
Ярларына сыенып йоклады.

Балыкчы карт яр буенда йөрми,
Күптән көтә көймә хуҗасын.
Яннарына барсаң, тынып тормас,
Сөйләр кебек үзенең нужасын.

Сандугачың кайда канат кага,
Былбылларың очкан кай якка?
Шау-шуларың булсын куанычлы,
Тынлыгыңда калмыйм озакка.

Суларыңны чайкап, дулкын, уят,
Җилләр уйнат кыя-ташында.
Акчарлаклар кайтсын ераклардан
Язгы ташкыннарның каршына.

## ЯЗЛАР ЯМЕ КҮҢЕЛЕМДӘ

Күкләр үз төсенә керде,
Җирдә карлар эреде.
Еракта, офык читендә,
Тәүге күкрәүләр йөрде.

Тирәкләр бөре чыгарган,
Җиргә калыккан үлән.
Сокландырган гүзәллек бар,
Яз китергән ямь, беләм.

Кояшлы, якты көннәрем,
Таралды болытларым.
Хисләр таша, дәртем арта,
Кадерле минутларым.

Язлар яме күңелемдә,
Бер җыр итеп атармын,
Бер мизгелен күзаллыймын,
Гомер буе мактармын.

## БАЗАР

Юл буйлары, урам чатларында
Тынлыкларың инде җуела.
Җәяүлесе, аты, машинасы
Базар мәйданына җыела.

Халык ташкынына кушылырга,
Ашыктыра мине йөрәгем.
Булган шатлыкларым тулы кебек,
Кеше эзли һаман кирәген.

Базар башында ук берәү баскан,
Билбау тоткан, тезгән шөшлесен.
Икенче бер кеше бәхәсләшә,
Үз хакың, ди, нишләп төшмисең?

Алганы да, сатканы да монда,
Сатулаша һәркем бу чакта.
Малы бары бушка ычкындырмый,
Чылбырыннан тоткан эт сата.

Шаулап торган базар чатларында,
Уртаклаша кызлар шатлыгын.
Ак сакалын җилдә җилфердәтеп,
Картлар сата балта сапларын.

Танауларга керә суган исе,
Алмалар күп, кергән хөрмәсе.
Җаның теләгәнен табып була,
Кирәк кешегә бар һәммәсе.

Табыш эзләп чыккан кешеләр бар,
Мыштым гына, әдәп саклыйлар.
Адәм баласына мал табыла,
Тик намусны гына сатмыйлар.

## КАР ЯВАРМЫ, ӘЛЛӘ ЯҢГЫРМЫ

Төн яктыра, офык чите алсу,
Урыныңа һаман ятмадың.
Күз карашың моңсу, томан баскан,
Керфегеңә керфек какмадың.

Өй алдында нарат башын чайкый,
Давыл тоеп, ахры, сызлана.
Кар явармы, әллә яңгырмы,
Җәрәхәтең әти кузгала.

Барометр угы кебек үзең,
Ни буласын алдан беләсең.
Кояшлы көн балкып туасын,
Яшен чатнап яңгыр явасын.

Күңел тынычлыгың югалткансың,
Урыныңда йокы тапмыйсың.
Күз өстенә төшкән ак шикелле,
Тәнеңдә син яра саклыйсың.

Яраларың сызлый, әрни инде,
Авыр итеп чыга сулышың.
Бетмәс газапларын-михнәтләрен
Күп күргәнсең, беләм, сугышның.

Кеше җирдә тик бер генә яши,
Аның кадерен син дә беләсең.
Үлем белән тормыш алышканда,
Гомер юлы буйлап киләсең.

## ХЫЯЛ КАНАТЛАРЫМ ЯРАЛЫ

Сугыш еллары да, ачлыгы да,
Туры килде малай чагыма.
Хәтеремнән юып ташламадым,
Моңсулыгым йөздә чагыла.

Якты язлар итеп күзалладым,
Киләчәкне җырда көйләдем.
Бушка гына булды юрауларым,
Хыял канатларым көйрәде.

Дала кошы сыман иркенлекне,
Чиксезлекне җаным теләде.
Бу тормышның михнәтеннән башка,
Юанырлык назын күрмәдем.

Исерекләр, бурлар, фахишәләр
Арасына килеп юлыктым.
Азган-тузган адәм балалары,
Гамьсез кешеләрдән курыктым.

Хыял канатларым яраланды,
Бу заманнан нәрсә көтәмен?
Тормыш шау-шулары уртасында,
Бәргәләнеп яшим күптән мин.

## СҮЗСЕЗ КАЛДЫК

Төштә күргән кебек кенә булды,
Бер-беребезгә тордык карашып.
Тормыш хәлләрен дә белəлмәдек,
Өлгермәдек хәтта сорашып.

Син дә мине күргәч тынып калдың,
Сүз кушарга мин дә кыймадым.
Вакыт узган, озак күрешмәдек,
Бары үсмер чакны уйладым.

Горурлык та, масаю да түгел,
Моңсу караш барысын яшерде.
Сагышларым ташып чыкса да мин,
Күрсәтмәдем кайнар яшемне.

Икебездә бер үк сорау туды,
Бәхәскә дә шуңа кермәдек.
Яшьлек елларыбыз күптән үткән,
Икебез дә бик нык үзгәрдек.

Юлларыбыз ята төрле якта,
Башың иеп киттең уйланып.
Без аңлаштык сүзсез генә барын,
Ә мин сиңа карыйм әйләнеп.

## СИЗДЕРМӘСКӘ ТЕЛИМ

Сиздермәскә, белдермәскә телим,
Тыныч көннәремне югалттым.
Көткән бәхет кошым килер диеп,
Күңелемне күптән юаттым.

Адашып та йөрдем юллар тапмый,
Тигез җирдә кайчак абындым.
Берәүләргә мәрхәмәтле булдым,
Берәүләргә каты кагылдым.

Үзем егылганда зарланмадым,
Гаебемне эзлим азактан.
Язмыш белән мин бәхәскә керәм,
Сызлаганда йөрәк газаптан.

Татлы хыял кочагында калам,
Уйларыма кайтам кабаттан.
Сугылдым да, бәрелдем дә кинәт,
Канатымны мин дә канаттым.

Канатларым җиргә сугылса да,
Югарыга табан үреләм.
Күп чак саксызлыктан яраланам,
Тормыш сөеп тагын тереләм.

## ҮЗГӘРӘ ДӨНЬЯСЫ

Малай чакта күп талады,
Әтәчләр, ата казлар.
Авылларга ямь китергән,
Хәтердә калган язлар.

Кызык итеп, мәзәк күрдем,
Бер нәрсә уйламадым.
Кемгә булса да берәүгә,
Ачу да җыйнамадым.

Иләсләнеп йөргәнгәме,
Юк-барга да көлгәнмен.
Туган җирнең гүзәллеген,
Матурлыгын күргәнмен.

Авыл урамын шаулаттык,
Малайлар белән бергә.
Уйнап-көлеп бер ваемсыз,
Яшәп булмый гомергә.

Үзгәрде хәзер дөньясы,
Юаш ата казлар да.
Озак көттереп килә шул,
Соңга кала язлар да.

## ЙӨРӘК САГЫШЛЫ

Йөрәгемне сагыш алды,
Сүнми дә, сүрелми дә.
Көйрәп яткан учак төсле,
Ялкыны күренми дә.

Күңел җәрәхәте бетми,
Юанырга юк чара.
Җил искәндә таллар да бит,
Башларын җиргә ора.

Таллар булып бөгеләмен,
Югалтуга тарыдым.
Тынгысыз көнем борчуда,
Шау-шуыннан арыдым.

Ярсу ат хәлендә калам,
Урын юк, җаным түзми.
Бер бушанырга исәбем,
Ничек тә әмәл эзлим.

Күптөрле кичерешләрем,
Мин калам исән-тере.
Сагышымны юып алыр,
Сайраган кошлар теле.

## КАРАШЫМНЫ ТӨБИМ

Карашымны төбим еракларга,
Кай җирләргә җитеп тукталыр.
Уйларымны, фикерләрне бергә,
Җыеп алган нинди ноктадыр.

Һәр тарафка күк чатырын ачкан,
Назын бирә баскан җиремә.
Каен яфрагыннан ширбәт булып,
Чык бөртеге тама иренгә.

Уйларымның очын табалмыйча,
Иләсләнеп торган минутым.
Табигатьнең ямьле кочагында,
Җаным тынычлыгын оныттым.

Тонык кына күкрәү таушы килә,
Тизләтәме сулар агышын.
Сәхрә-кырларымда көнем уза,
Таратамын күңел сагышын.

Табынып та, кагынып та карыйм,
Үз хәлемне аңлап бушанам.
Карашымны төбим офыкларга,
Туар таңнарыма ышанам.

✿

* * *

Хәвеф-хәтәр читләп үтми,
Бер-бер артлы килеп тора.
Хөсетлек кылган бәндәләр,
Шәп булды дип, көлеп тора.

Елан булып ысылдыйлар,
Җан яралап килеп чага.
Ярдан ашкан кар суыдай,
Ачы нәфрәт ташып чыга.

Гаепсезне хөкем итә,
Йорт-илемә таш аталар.
Ничек кенә үч алырга,
Гамьсез җаннар баш ваталар.

Кайчак көчем җитми кала,
Шикләнмәдем, яшермәдем.
Яшен сыман яшьнәсеннәр,
Берсенә дә баш бирмәдем.

## ТЫНЛЫК ЭЗЛИМ

Шәһәр шау-шулары ялыктырды,
Тынлык эзлим, тынчу һавасы.
Ыгы-зыгы белән үткән көнгә,
Ияләнми авыл баласы.

Таш капчыкка төшкән төсле тоям,
Тансык итәм авыл иртәсен.
Яшьлек ямен күздән кичерәмен,
И, сабырсыз күңел көтәсең.

Туган якка җае чыккан саен,
Кошлар кебек кайтам ашкынып.
Дөнья мәшәкате кулны тота,
Бик еш булмый аннан ычкынып.

Туган туфрагымда тамырларым,
Өзелмәгән — шуны аңладым.
Ерак яшим, җаным риза түгел,
Язмышымнан һич тә уңмадым.

## КҮЗЛӘРЕМДӘ ЯШЬЛЕК ДӘРТЕ

Юлларыма яңа юллар кушыла,
Елларыма еллар өстәлә.
Туган көннең шаулы тантанасы,
Бергә җыйды безне өстәлгә.

Маңгай бөдрәләрен сирәкләтеп,
Чәчләремне еллар агартты.
Табыннарда безнең җырланган җыр,
Яшьлек хатирәсен яңартты.

Күзне ачып йомган ара гына,
Бөтен гомеремнең үткәне.
Матурлыкны, көчне, дусларымны,
Мин югалтып яшим күпләрне.

Узган еллар төшкә генә керә,
Тик сагышка сала күзләр дә.
Күктә калган соңгы йолдыз сыман,
Яшьлек дәрте балкый күзләрдә.

## ИҖАТ ЯЛКЫНЫ СҮНМӘСЕН

Күңел түрендә кабынды,
Иҗат учагым.
Йолдызлар булып балкыймын,
Минем шул чагым.

Шәмнәр кебек дөрләп янам,
Давылда, җилдә.
Гауга, алыш беткәне юк,
Мәңге бу илдә.

Хәтәр заманда туганмын,
Күптән аңладым.
Максатыма юл ярганда,
Тормыш, алдадың.

Ихтыяр көчем җитәрлек,
Шатлык кичерәм.
Яшәү хакы арзан түгел,
Таулар күчерәм.

Тормыш адым саен сыный,
Тоямын көн дә.
Иҗат ялкыны сүнмәсен,
Гомергә миндә.

## ЮГАЛТМАЕК КАДЕРНЕ

Кайгы-хәсрәт килеп ишек кага,
Тансык түгел, көтеп алмадым.
Өметләрем чынга ашмый кала,
Тормыш, мине бик күп алдадың.

Минем белән уйный күпләр һаман,
Бушка китте әзме эшләрем?!
Таш стена сыман басып торам,
Иренемне шунда тешләдем.

Баш өстендә кара болыт йөри,
Аяз түгел нигә күкләрем?
Гаделсезлек күрдем бу тормышта,
Яшьләремне юкка түкмәдем.

Үз кардәшем, дустым итеп саныйм,
Кешеләргә ихлас ышанам.
Мин террорист түгел, шикләнмәгез,
Беркемнән дә һич тә үч алмам.

Шәфкать бетеп бара бу заманда,
И, кешеләр каты бәгырьле.
Мәрхәмәтсез, гамьсез кыланабыз,
Кадерсезнең калмый кабере,
Югалтмаек без дә кадерне.

## ТЕЛӘГЕНӘ КЕШЕ ИРЕШӘ

Ашкынып та, җилкенеп тә көтә,
Кызлар көтә һәрчак көз аен.
Көзләр җиткәч каз өмәсе уза,
Туйлар үтәр тагын мөгаен.

Кем дә өмет багалыйдыр инде,
Киләчәген күптән көтәдер.
Мәхәббәтен, бәхет эзләп йөргән,
Андый кешеләр дә күпләрдер.

Якты көнне, алсу таңны көттем,
Яшәү ямен өсти ләззәте.
Хыялларым ак канатын кагып,
Килер шатлыгымны тизләтте.

Заман дәшә кыюларга тиңләп,
Олы хисләр җанны җилкетә.
Бөек эшләр, зур җиңүләр белән,
Матур киләчәкне ил көтә.

Өметләрең генә өзелмәсен,
Вакыт кыла хөкем төрлечә.
Илләр тыныч, еллар имин булса,
Теләгенә кеше иреша.

## БӘЙРӘМНӘРНЕ КӨТЕП АЛАМ

Малайлары җыелып ат чаптыра,
Тай өйрәтә чыккан болынга.
Әбиләр каз бәбкәсе саклый,
Тал чыбыгы тотып кулына.

Болын буе шаулы, атлар кешни,
Җирән кашка, алма чаптары.
Хыял канатларын вәгъдә иткән,
Егетләрнең ярсу чаклары.

Сабан туе якынлашып килә,
Хезмәт тантанасын китерә.
Яшьләр бәйрәм хәстәрлеген күрә,
Кызлар матур күлмәк тектерә.

Ат чаптырган малайларның нигә,
Түгел икән хәзер берсе мин?
Мәхәббәтем яңа бөреләнгән,
Унсигезем тулган төслемен.

Бәйрәмнәрне алдан көтеп алам,
Якты хисләр миндә кабына.
Җан дусларым, ахирәтләр килсен,
Куанычлар уртак табында.

## ИРЛӘРНЕҢ ТӨРЛЕСЕ БАР

Ирләрнең дә төрлесе бар,
Зарланганы, мескене.
Кайчагында юк-барга да,
Зар елаган «мөшкеле».

Усаллар үзен күрсәтте,
Ялагайлар танытты.
Якамнан тотып алып,
Борынымны канатты.

Сәбәпләрен белми калдым,
Башыма кемдер сукты.
Көнчелләрнең беткәне юк,
Юлыма каршы чыкты.

Акланырга, мактанырга,
Булсам да кайчак хаклы.
Булдыксызга санаучылар,
Күптөрле ярлык такты.

Сабырлыгымны җыямын,
Җаныма булсын терәк.
Ирләр булып калыйм дисәң,
Ихтыяр көче кирәк.

## БОЛЫН

Чык бөртеген кояш ялап ала,
Үләннәр дә кибеп өлгерде.
Чәчәкләрдән чәчәкләргә кунып,
Күбәләкләр уйнап йөреде.

Болын кочагында назлы гөлләр,
Күрү белән күзләр камаша.
Колын чаба, казлар каңгылдаша,
Җан иясе кыла тамаша.

Бал кортлары оча баш очыннан,
Белмим, алар кая ашыга.
Ширбәт тама керфек очларыннан,
Асыл гөлләр җыям учыма.

Күбәләкләр куып малай йөгерә,
Карамый ул бер дә артына.
Болын матурлыгын күреп монда,
Бөтен борчуларым онтыла.

Йөрәк тарый якты хатирәгә,
Сукмагыннан сөенеп атлыйсың.
Гомер язларымны синдә таптым,
Яшьлек ямен болын саклыйсың.

## КИЛӘЧӘККӘ ЮЛЛАР БАРА

Ир-егетләр баскан юл чатына,
Кая китсәләр дә ирекле.
Күрәчәкне юллап, күрәсеңдер,
Ирек куйган язмыш бу тикле.

Җиде якка җиде юл сузылган,
Теләгәнен сайлап аласың.
Нинди табыш, нинди һәлакәткә,
Очрамас адәм баласы.

Юллар төрле. Берсе илтә данга,
Икенчесе аның афәтле.
Күк артына ыргытмаслар әле,
Безгә тигән олы бәхетне.

Дәрәҗәгә-данга мендермәдең,
Юл газабын бары күрсәттең.
Дусларыма хәтта сиздермәдем,
Олы башы төште күсәкнең.

Кеше генәме соң хәрәкәттә,
Сулар агып бергә катнаша.
Юллар уза кышлар, җәйләр аша,
Киләчәккә барып тоташа.

## ТӨРЛЕ ХӘЛЛӘР БУЛА

Төрле хәлләр баштан узды,
Беркемнән үч алмадым.
Җиңел яшәп буламы соң,
Бу тормышны аңладым.

Бер генә яшим дөньяда,
Калыр йөргән сукмагым.
Горурлык хисе җанда бар,
Намусымны сакладым.

Имәннәр кебек чайкалам,
Җир шикелле тетрәнәм.
Иңгә төшкән авырлыкны,
Берьялгызым күтәрәм.

Баш өстендә болыт йөрде,
Аяз тормый күк йөзе,
Бик кечкенә табышка да,
Төшә ятларның күзе.

Дөньяны күреп таныдым,
Әйтергә дә хакым бар.
Әз генә эш күрсәтсәм дә,
Мактый торган халкым бар.

## КҮРЕШҮ КӨНЕН КӨТӘМ

Хушлашмадың китеп бардың,
Миндә уйлар кузгатып.
Күзләремнән югалтканчы,
Карап калдым озатып.
Киттең уйлар кузгатып.

Син киткән якларда балкып,
Таңнар сызылып атты.
Җил шаяртып каеннарның,
Яшел чугын таратты.
Хисләремне яңартты.

Сезнең яктан кошлар кайтты,
Тирәкләрдә кагына.
Юксынып яшимен хәзер,
Сагыш җанга кагыла.
Күңел сиңа табына.

Кабул итәм аткан таңны,
Кайнар сәламең итеп.
Өметләнеп мин яшимен,
Сөю язларын көтеп.
Гомерләр бара үтеп.

## РӘХМӘТ, ЯЗМЫШ

Урал урманнарын кистем,
Күмер ташларын ваттым.
Хезмәт җимешемне җыеп,
Олы куаныч таптым.

Бәхетемне эзләп килдем,
Күз күрмәгән якларга.
Авылымны бик сагынып,
Җырлар яздым хатларга.

Өмет белән яшәгәнгә,
Җитә ихтыяр көче.
Авырлыклар күргән саен,
Түземле була кеше.

Тормыш сынауларын үттем,
Сынмадым, сыгылмадым.
Нинди юлларда йөрсәм дә,
Юк, арып егылмадым.

Ата-бабам изге эшен
Үземә өлге иттем.
Рәхмәт, язмыш, соклanырлык,
Булдыклы егет иттең.

## КЫШ МИЗГЕЛЕ

Дәрья тавышлары тынып калган,
Ярлар күк бозларга төренгән.
Ташу сулар кебек ургып чыкты,
Сагышларым йөрәк түреннән.

Килер язны көтеп юксынамын,
Миңа тансык чәчкә-гөл исе.
Биләүләрдә әле йоклап ята,
Тирәкләрнең яшел бөресе.

Ак моңнарга тулы кыр өсләре,
Сәхрәләргә илтә сукмагым.
Җилләр тарый, сөеп-назлап кына,
Бәскә каткан каен чукларын.

Әллә кардан, әллә каеннардан,
Җир өстенә төшкән аклык бар.
Бәйрәм төсе керде тирә-юньгә,
Кыш тантана итә, хаклык бар.

## СОҢГЫ ЮЛГА ЧЫКТЫҢ

*Әтигә багышлыйм*

Кара шәлен кайгы иңгә салды,
Таллар сыман мин дә бөгелдем.
Утлар йоттым, дөрләп яндым үзем,
Сулар булып җиргә түгелдем.

Соңгы юлга, әти, син чыгасың,
Мәңгелеккә йомдың күзеңне.
Хушлашабыз, вакыт җитте инде,
Ничек кулга алыйм үземне.

Томан басты бөтен күз алдымны,
Тау кадәрле булды хәсрәтем.
Көтмәгәндә, уйламаган чакта,
Күбәләктәй җанны тетрәттең.

Иртә-кичен әҗәлеңне көттең,
Сугыш яраларың сызлады.
Кешеләргә бер дә зарланмадың,
Сабыр булдың, түздең, чыдадың.

Югалтуны авыр кичерәмен,
Күгем, җирем бергә тоташты.
Дөнья ак-карасы күренмәде,
Иреннәрем кибеп тартышты.

Әйтелмәгән васыятьләрең калды,
Бергә узган еллар кадерле.
Кошлар әйтеп сайрар сагынуымны,
Җилләр үбәр сөеп кабереңне.

## КӨННӘР ЙОНЧУ БЫЕЛ

Быелгы ел әллә ничек килде,
Кышы кышка охшаш булмады.
Бурап-бурап карлары да яумый,
Чеметмәде салкын кулларны.

Январь уртасында яңгыр яуды,
Кыйбла якка җиле борылды.
Ташу сулар кебек болыт акты,
Дымсу һава ярды борынны.

Җәе-кышы бергә буталганмы,
Мәрхәмәтен таймыйм кояшның.
Яшел үләннәргә чыклар төшкән,
Ямьле җәй айлары кая соң?

Яз да быел соңлап кына килде,
Вакытында бозлар китмәде.
Әкрен генә сызып эри карлар,
Сукмак-юллары да кипмәде.

Сары көзләр бик ашыгып килде,
Иртә төште ап-ак кыраулар.
Еллар арык, көннәр йончу быел,
Үз җавабын көтә сораулар.

* * *

Тәрәзәмә карлы яңгыр ява,
Җилләр улый, төне караңгы.
Ел фасылы алмашынып тора,
Эч пошыра шомлы карары.

Җанга тия бөтен моңсулыгы,
Миңа тансык язның күкрәве.
Юксынганда кулым эшкә бармый,
Сискәндерә күңел тетрәве.

Бишегендә яткан бала кебек,
Тыныч калалмадым белмичә.
Учагымда янган утлар сүнде,
Йокыларны бүләм мин ничә.

Шат көннәрем калды, кайда торып,
Сулар булып акты кай якка.
Мин төн белән ялгыз серләшәмен,
Ят авазлар керде колакка.

Сәгать телләренә күз төшерәм,
Әкрен уза төндә вакытлар.
Дөнья фанилыгы кисәтәме,
Инандырган монда хаклык бар.

## БАРЫСЫН ДА КҮРСӘТТЕ

Ак биләүгә төреп сөендердең,
Бишегемә салып тирбәттең.
Явызлыкны, изгелекне беләм,
Аерырга, дөнья, өйрәттең.

Гомер буе явызлыктан качам,
Яхшылыкка карап юл алам.
Изгелекне, дөреслекне юллап,
Күпме вакыт бушка югалган.

Акланмыймын сәбәпләрен эзләп,
Кемгә калган аның кирәге.
Вакытында йөрәк янды тетрәп,
Тормыш утларында көйрәде.

Гомеремнең шаулы чагы узды,
Ярсу хисләремнән бушанам.
Язлар үтте, сары көзләремне,
Моңсуланып ялгыз каршы алам.

Киләчәгем мине уйландыра,
Төшләремә кереп кисәтте.
Дусларны да бирде, дошманны да,
Барысын да дөнья күрсәтте.

## МӘҖЛЕСТӘ

Икмәкләргә, сыйга тулы чагы,
Өстәлләргә тезеп куелган.
Шаулап тора, гөрләп тора бүген,
Табыннарга дуслар җыелган.

Танышларым матур елмаялар,
Күркәмләтеп матур табынны.
Гармун моңы, җыр авазы белән,
Күзләремдә ялкын кабынды.

Мәҗлесләрдә шатлык кичерәмен,
Сый-хөрмәтнең күрәм олысын.
Бергә чакның без кадерен белик,
Тост күтәрик, тотыйк тулысын.

Гомерлеккә хәтерләрдә калсын,
Бергә булган ямьле сәгатьләр.
Очраштырмый безне, күрештерми,
Бу тормышта төрле сәбәпләр.

Сый-хөрмәт күп, табыныбыз җырлы,
Кардәшлекне бергә ачыклыйк.
Юлларыбыз төрле якка үтә,
Таралырга, дуслар, ашыкмыйк.

## ГАРМУНЫМ КУЛЛАРЫМДА

Гармун дустым, синең белән,
Яшь чакта ук таныштым.
Дәртле, моңлы, җырлы иттең,
Гомеремнең агышын.

Икәү бергә бик күп йөрдек,
Мәҗлесләрдә, туйларда.
Гармун моңына көнләшә,
Сандугач та, тургай да.

Йөрәк серемне сөйләтәм,
Гармуным телләреннән.
Исән-имин алып чыга,
Хәсрәт күлләреннән.

Кайларга гына барсам да,
Кулымнан һич куймадым.
Урамнарда, сәхрәләрдә,
Гармунымны уйнадым.

Талпынсын, кагынсын әле,
Туган җирдә талларда.
Җыр белән гомер кичерәм,
Гармуным кулларымда.

## ЧӘЧКӘ КУЯМ ӘТИ КАБЕРЕНӘ

Әти, каберең\u0259 килдем синең,
Уян әле, чәчкә китердем.
Салкын кышлар мәшәкатьле узды,
Кичер мине, озак көттердем.

Җир куйнына мәңгелеккә кердең,
Тирән йокыларга талгансың.
Төшләремә кереп кисәтәсең,
Аңлашырга җаен табасың.

Тормыш үзгәрмәде уңай якка,
Ил мөлкәтен күпләр талыйлар.
Кол хәленә калып халык яши,
Гамьсез җаннар көлеп карыйлар.

Сугыштагы алган яраларың,
Төзәлмәде, салды кабергә.
Оныкларың Чечен җирен яулый,
Имин түгел илем хәзер дә.

Язмышларда, әти, уртаклык бар,
Кем күрәлде тормыш рәхәтен.
Көткән солдат табут белән кайта,
Бетми илдә сугыш афәте.

## ЯШЕН

Күк гөмбәзен тетрәтә,
Яшеннәр чатный уйнап.
Офыклардан аваз килә,
Ерак галәмнәр буйлап.

Биек таулар чүккән сыман,
Аккан сулар чайкалды.
Шомлы күкрәү тавышына,
Бар табигать тын калды.

Гайрәтен, көчен күрсәтеп,
Утлы яшен уйнады.
Котын очырып кешенең,
Камчылады дөньяны.

Галәм битараф калмады,
Күкрәү тавышына.
Хөкемен чыгара тагы
Ул кемнең язмышына.

* * *

Мин дә горурлык хисе кичердем,
Чибәрлек тә, көч тә бар иде.
Ураганда тальян гармун белән,
Авыл урамнары тар иде.

Гомер язларымда айлы кичләр
Гүзәл яшьлегемне назлады.
Гел шатлыктан, куанычтан гына,
Бер-бер артлы еллар узмады.

Хыялларым чәчәк аткан мәлдә,
Мин дә сөйдем, мин дә сөелдем.
Курчак тоткан сабый бала төсле,
Ихлас күңелемнән сөендем.

Бәйрәм иткән көнем бер төш кенә,
Мине сала тормыш утына.
Шат көннәрем, көләч яшьлегемдә,
Торып калды томан артында.

Көч тә кими, матурлык та бетә,
Сүнеп кала якты караш та.
Бу дөньяда үзгәрмичә калмый,
Эреп ага тимер-корыч та.

## ВАКЫТ ХӨКЕМЕ

Күккә ашып торган таулар чүгә,
Дәрья суы бора агышын.
Ерак гасырларга алып китә
Без яшәгән еллар тавышын.

Таш ватыла, тимер эреп ага,
Әверелә бар да туфракка.
Сәгатендә коя соңламыйча,
Агачларда калмый яфрак та.

Мәңгелеккә җирдә урын бармы?
Без табынган дөнья фанимы?
Кеше вакыт хөкемендә кала,
Мишень итеп еллар саныймы.

Узган гомер җилгә оча сыман,
Чакырып алалмыйсың кирегә.
Якты төсләр, матур бизәкләр дә
Соңгы чиктә төссез күренә.

Дөнья мәйданына чыгарганда,
Читтә калмый аннан шәхес тә.
Һәр дәвереӊ даһиларын таба,
Вакыт белән кермим бәхәскә.

## БАЛ КОРТЛАРЫ

Бакча уртасында умарталар,
Сары, көрән төскә буялган.
Сызылып кына таңнар аткан мәле.
Бал кортлары күптән уянган.

Челтәр пәрдәләрен томан япкан,
Үзәннәргә, таулар куйнына.
Яшел яфраклардан шыбыр-шыбыр
Көмеш тәңкә җиргә коела.

Тыныч күге, җиләс иртәләре,
Йорт ишеге, капка ачыла.
Арлы-бирле оча бал кортлары,
Болыннарга, кырга ашыга.

Юкә агачлары шау чәчәктә,
Бал кортлары куна таҗына.
Көн башлана хезмәт дәрте белән,
Җан тынлыгын белми аз гына.

Чәчкәләрдән хуш ис, ширбәт аңкый,
Үз сагына ала хәтерем.
Кешеләр күк бал кортлары эшчән,
Белә икән тормыш кадерен.

## ЯЗГЫ ҖИЛЛӘР

Җилфер-җилфер язгы җилләр исә,
Агачларның сөеп бөресен.
Күк сәламен бүләк итте миңа,
Илләр гизеп армый йөрисең.

Буразналар буйлап йөгереп уздың,
Канат кактың басу түрендә.
Каеннарның чәч толымын сүттең,
Бар шөгылең миңа күренә.

Урамнарга ятып сызгырасың,
Дәрьяларда дулкын уяттың.
Яр башында таллар биеп тора,
Курайларны моңлы уйнаттың.

Язгы җилләр тәрәзәмне ачты,
Челтәр пәрдәләрен күтәрә.
Яшел үзәннәрнең җиләслеген,
Бөре исен миңа китерә.

* * *

Төн артыннан көткән көнем килә,
Мин бәхетле шушы минутта.
Беркайчан да тыныч чагым булмый,
Сабырсызмын, бәлки, мин юкка.

Язмышыма бер дә ачынмадым,
Адаштырып йөртте еракта.
Печәнен дә чапкан авылдашлар,
Серкәләнә арыш мин юкта.

Уйландыра, төрле чагым була,
Була кайчак авыр минут та.
Күңел бер дә сагынмыйча тормый,
Туган җирне кем соң оныта?!

## МОҢСУ ЧАГЫМ

Көн артыннан көннәр үтә,
Ел артыннан ел уза.
Картлыгым да килеп җиткән,
Таягын миңа суза.

Яшьлек елларым еракта,
Һәрчак керә төшемә.
Гомерләр уза да китә,
Йөрәк шуңа төшенә.

Җанымны юата алырмы
Киләчәк матур көннәр?
Зарланып, уфтанып киткән,
Дөньядан әллә кемнәр.

Яраладым йөрәгемне,
Соңгы чиктә кем аклар.
Үткәннәрдән киләчәккә,
Алып килә сукмаклар.

Миннән соң да язлар килер,
Ташып, ярсып агар су.
Уйланыр көнгә җиткәнмен,
Шунысы бигрәк ямансу.

## МАЛАЙ ЧАКЛАР КАЙДА КАЛДЫ?

Кичә генә без малайлар идек,
Шау-гөр килеп бергә уйнадык.
Болын буйларына йөгереп чыктык,
Урам чатларында җыйналдык.

Ул чакларда дөнья кызык иде,
Чирәмнәргә ятып аунадык.
Йокылардан тордык егет булып,
Гомер узганлыгын аңладык.

Нинди юлда, нинди сукмакларда,
Малай чагым калды адашып.
Еллар, айлар, көннәр, төннәр уза,
Бер-бер артлы тора алмашып.

Бергә үскән дуслар юксындырып,
Йөрәгемнән китми һаман да.
Бүген үзем кебек малаем да,
Йөгереп, уйнап йөри урамда.

## ЯЛГЫЗЛЫК

Ялгызлыгым гел кисәтә,
Иртәсен дә, кичен дә.
Җаныма бер тынгы бирми,
Хәтта күргән төшем дә.

Гомер буе ялгызлыкның
Мин газабын кичерәм.
Сагындыра җан дусларым,
Һәрчак искә төшерәм.

Күп дусларым дөнья куйды,
Хәзер белмим, нишләрмен?
Ятим калган малай кебек,
Моңсулана хисләрем.

Кайгымны кемнәр уртаклар,
Серемне кемгә сөйлим.
Язмыш кулыннан ычкынып,
Китәргә күптән телим.

Ялгызлык яралар салды,
Йөрәгемне сызлатыр.
Соңгы юлга киткән чакта
Мине кемнәр озатыр?

## ҖИР

Җир шары урый,
Күчәре буйлап.
Дөнья хәлләрен,
Яшимен уйлап.

Йолдызлар көлеп,
Карашын төби.
Сәламен бирә,
Серләрен сөйли.

Сокландыра гөл,
Бетмәс назлары.
Чәчкәгә күмә,
Матур язлары.

Җир күкрәге киң,
Тавы, күле бар.
Кояшлы, айлы,
Төне, көне бар.

Яшьлек ямьнәре
Җирдә саклана.
Сере мәңгелек,
Һәркем соклана.

* * *

Җир шикелле кинәт тетрәп куям,
Йон йомгагы булып сүтеләм.
Бу тормышта яшәвемне раслап,
Дәгъвалыйммын, кайчак үтенәм.

Эчкән суларымның тәме бетте,
Авыр итеп сулыйм һавасын да.
Нинди фаҗигале хәлгә җиттек,
Афәт яный адәм баласына.

Таркалганда атомнарың шартлап,
Дәрья сыман чайкый җирләрне.
Галәм капкаларын кагып килә,
Давыл юллап йолдыз җилләре.

Заман чире безне читләп үтми,
Һәр кешегә килеп кагыла.
Икмәгемнән, эчкән суларымнан,
Нитрат керә минем каныма.

Иртәгәсе көнне күзаллыймын,
Кайда соң ул безнең кыйблабыз.
Киләчәккә барып җитә алырлык
Нинди изге эшләр кылабыз?

## ТӨННӘР БУЕ ЧИГҮ ЧИГӘСЕҢ

Әни,
Керфегеңә йокы кунган инде,
Төннәр буе чигү чигәсең.
Чекерәеп тонык ут каршында
Күзләреңнең нурын түгәсең.

Кулың талган, ефәк җепләр сайлап,
Бертуктаусыз һаман кайныйсың.
Сагынуыңны беләм:
Күңел күзе аша
Үткән яшьлегеңә карыйсың...

## КӨЗГЕ МОҢ

Торналарның саубуллашкан мәле,
Күк йөзләрен телеп икегә.
Туган җирен ташлап киткәнгәме,
Өзгәләнә бар да, үкенә.

Агачларым яфракларын түгә,
Җилләр сузып көйли кубызын.
Урман аланында кызыл ялкын,
Миләш учакларын кабызган.

Моңсу булып таулар башын игән,
Төссезләнде тәмам офыклар.
Агымсулар тоныклана бара,
Мондый хәлне кем дә ачыклар.

Бакчамдагы гөлләр тибрәләләр,
Моңсу карап минем күзләргә.
Йөрәгемә салып сагышларын,
Мин кергәнмен сары көзләргә.

Моң эчендә калам: тезгенләде,
Уйларымны барып бәйләде.
Күбәләкләр кебек очып төшә,—
Тирә-юньдә яфрак бәйрәме.

## ВАКЫТЫМ ЮК

Көне, төне бергә тоташ ага,
Туктап тормый вакыт ашыга.
Мең елдан соң ниләр булыр икән,
Торып бассаң кабер ташына.

Җир күкрәге иркен, җыя барсын,
Исем, фамилиясен сорамый.
Үлем тез чүктерә кешеләрне,
Дәрәҗәгә, данга карамый.

Йөз яшәрдәй хәтәр кыланабыз,
Фанилыгын белми дөньяның.
Агач яфракларын койган мәлне,
Моңсуланып бераз уйландым.

Күзен йомды таңда карт ветеран,
Кемнәр китәр тагын иртәгә.
Әҗәл үзе эзләп килер бер көн,
Вакытым юк аны көтәргә.

## БОЛГАР ҖИРЕ

Күк томаннар аша кәрваннар
Мәдинәдән килгән, Мәккәдән.
Гүзәллеген, матурлыгын күреп
Болгар җирен алар мактаган.

Тирә-юньдә карурманнар шаулап,
Ташып торган дәрья сулары.
Җырлар итеп халык җырлый аны —
Бер легенда итә чорларны.

Болыннарда ат көтүе йөргән,
Күктә — киек кошлар төркеме.
Болгар иле — хәзинәле дәүләт —
Кунак кабул иткән һәр көнне.

Шәһәр урамнары шаулап торган,
Ташпулатлар киткән тезелеп.
Ай балкытып мәчетләре торган,
Манаралар белән бизәлеп.

Гөл бакчасы кебек чәчәк аткан,
Заманында Болгар дәүләте.
Дусларына ачык йөз күрсәткән,
Дошманына булган гайрәтле.

Иген иккән халык, сәүдә иткән,
Хезмәт сөйгән кеше — дан тоткан.
Безнең көнгә калган исемнәре,
Кемнәрнедер еллар оныткан...

Таш диварлар, биек манаралар
Узган чорның төсен саклаган.
Ата-бабам йорт нигезен корган,
Изге җирем, сиңа сокланам.

## ТАТАР ХАЛКЫ

Планетаның төрле почмагында
Күреп була татар кешесен.
Кайда гына алар яшәсә дә,
Рәнҗетмәде бер дә күршесен.

Татар халкы җирләр яуламады,
Канга батырмады дөньяны.
Илбасарлар кердe чиген үтеп,
Язмышында күпләр уйнады.

Йорт-илләрен утта яндырдылар,
Улын-кызын сатып коллыкка.
Узган гасырлардан урап кайта,
Богау чыңы керә колакка.

Манарасын кисеп мәчетенең,
Ташын алып чиркәү салалар.
Изге эшләр, тырышлыклар кала,
Бушка кала кылган чаралар.

Динеңнән ваз кичтерттеләр тәмам,
Аннан көчләп тәре тактылар.
«Татар явы» дигән үтә хәтәр,
Куркыныч бер исем таптылар.

Кимсетелде, газапланды халкым,
Ятлар торды һәрчак танытып.
Үз йолаңны, үз телеңне белми,
Яшәп булмый барын онытып.

Күп гасырлар ирек юлладылар,
Газап чигеп яшәү хакына.
Хөрмәт арта бөтен гомере буе
Тирен түккән татар халкына.

## ЯФРАКЛАР ДА СЕРЛӘШӘ

Агачлар шавын ишетәм,
Яфраклар да сөйләшә.
Яшь егетләр, кызлар кебек,
Үзләренчә серләшә.

Аяз көндә тыныч була,
Яфраклар да шәпләнә.
Кояшка кулларын суза,
Сабырлана, шатлана.

Бик аз гына җил иссә дә,
Яфраклар шомлана.
Әйтерсең дога укыйлар,
Шулчак күңел моңлана.

Күкләр дә күкрәп куя,
Яшен уты ялтырый.
Таулар ишелеп төшәрлек,
Җир өсләре калтырый.

Яфрак белән яфрак сердәш,
Сорашалар хәлләрен.
...Иминлегең ничек? — диеп,
Дөнья күзли илләрен.

## ЙӨРӘКТӘ САКЛЫЙМ

Йөрәгем, кыңгырау сыман,
Чаң кага, оран сала.
Яшәү хакына талпына,
Дөнья үзенә ала...

Үлән генә калтыransсын,
Йөрәк жу итеп китә.
Җиһанда нәрсәләр булмас,
Карашым кала күктә.

Көчсезлегем сәбәпчеме,
Бит очлары кызара.
Әйтерсең, йөрәкне телеп,
Яшен ташы кадала.

Җирдә яшәгәч, үз итә
Яңгыры, бозы, җиле.
Хәвеф-хәтәр янап тора,—
Бу бит — адәмнәр иле!

Якты көн кебек каршылыйм,
Барын да кабул итәм.
Җирнең гамен, күк балкышын,
Йөрәктә саклап йөртәм.

## КӨЗГЕ МОҢ

Торналарның саубуллашкан мәле,
Күк йөзләрен телеп икегә.
Туган җирен ташлап киткәнгәме,
Өзгәләнә бар да, үкенә.

Агачларым яфракларын түгә,
Җилләр сузып көйли кубызын.
Урман аланында кызыл ялкын,
Миләш учакларын кабызган.

Моңсу булып таулар башын игән,
Төссезләнде тәмам офыклар.
Агымсулар тоныклана бара,
Мондый хәлне кем дә ачыклар.

Бакчамдагы гөлләр тибрәләләр,
Моңсу карап минем күзләргә.
Йөрәгемә салып сагышларын,
Мин кергәнмен сары көзләргә.

Моң эчендә калам: тезгенләде,
Уйларымны барып бәйләде.
Күбәләкләр кебек очып төшә,—
Тирә-юньдә яфрак бәйрәме.

## ВАКЫТЫМ ЮК

Көне, төне бергә тоташ ага,
Туктап тормый вакыт ашыга.
Мең елдан соңниләр булыр икән,
Торып бассаң кабер ташына.

Җир күкрәге иркен, җыя барсын,
Исем, фамилиясен сорамый.
Үлем тез чүктерә кешеләрне,
Дәрәҗәгә, данга карамый.

Йөз яшәрдәй хәтәр кыланабыз,
Фанилыгын белми дөньяның.
Агач яфракларын койган мәлне,
Моңсуланып бераз уйландым.

Күзен йомды таңда карт ветеран,
Кемнәр китәр тагын иртәгә.
Әҗәл үзе эзләп килер бер көн,
Вакытым юк аны күтәргә.

## БОЛГАР ҖИРЕ

Күк томаннар аша кәрваннар
Мәдинәдән килгән, Мәккәдән.
Гүзәллеген, матурлыгын күреп
Болгар җирен алар мактаган.

Тирә-юньдә карурманнар шаулап,
Ташып торган дәрья сулары.
Җырлар итеп халык җырлый аны —
Бер легенда итә чорларны.

Болыннарда ат көтүе йөргән,
Күктә — киек кошлар төркеме.
Болгар иле — хәзинәле дәүләт —
Кунак кабул иткән һәр көнне.

Шәһәр урамнары шаулап торган,
Ташпулатлар киткән тезелеп.
Ай балкытып мәчетләре торган,
Манаралар белән бизәлеп.

Гөл бакчасы кебек чәчәк аткан,
Заманында Болгар дәүләте.
Дусларына ачык йөз күрсәткән,
Дошманына булган гайрәтле.

Иген иккән халык, сәүдә иткән,
Хезмәт сөйгән кеше — дан тоткан.
Безнең көнгә калган исемнәре,
Кемнәрнедер еллар оныткан...

Таш диварлар, биек манаралар
Узган чорның төсен саклаган.
Ата-бабам йорт нигезен корган,
Изге җирем, сиңа сокланам.

## ТАТАР ХАЛКЫ

Планетаның төрле почмагында
Күреп була татар кешесен.
Кайда гына алар яшәсә дә,
Рәнҗетмәде бер дә күршесен.

Татар халкы җирләр яуламады,
Канга батырмады дөньяны.
Илбасарлар керде чиген үтеп,
Язмышында күпләр уйнады.

Йорт-илләрен утта яндырдылар,
Улын-кызын сатып коллыкка.
Узган гасырлардан урап кайта,
Богау чыңы керә колакка.

Манарасын кисеп мәчетенең,
Ташын алып чиркәү салалар.
Изге эшләр, тырышлыклар кала,
Бушка кала кылган чаралар.

Динеңнән ваз кичтерттеләр тәмам,
Аннан көчләп тәре тактылар.
«Татар явы» дигән үтә хәтәр,
Куркыныч бер исем таптылар.

Кимсетелде, газапланды халкым,
Ятлар торды һәрчак танытып.
Үз йолаңны, үз телеңне белми,
Яшәп булмый барын онытып.

Күп гасырлар ирек юлладылар,
Газап чигеп яшәү хакына.
Хөрмәт арта бөтен гомере буе
Тирен түккән татар халкына.

## ЯФРАКЛАР ДА СЕРЛӘШӘ

Агачлар шавын ишетәм,
Яфраклар да сөйләшә.
Яшь егетләр, кызлар кебек,
Үзләренчә серләшә.

Аяз көндә тыныч була,
Яфраклар да шәпләнә.
Кояшка кулларын суза,
Сабырлана, шатлана.

Бик аз гына җил иссә дә,
Яфраклар шомлана.
Әйтерсең дога укыйлар,
Шулчак күңел моңлана.

Күкләр дә күкрәп куя,
Яшен уты ялтырый.
Таулар ишелеп төшәрлек,
Җир өсләре калтырый.

Яфрак белән яфрак сердәш,
Сорашалар хәлләрен.
...Иминлегең ничек? — диеп,
Дөнья күзли илләрен.

## ЙӨРӘКТӘ САКЛЫЙМ

Йөрәгем, кыңгырау сыман,
Чаң кага, оран сала.
Яшәү хакына талпына,
Дөнья үзенә ала...

Үлән генә калтырансын,
Йөрәк жу итеп китә.
Җиһанда нәрсәләр булмас,
Карашым кала күктә.

Көчсезлегем сәбәпчеме,
Бит очлары кызара.
Әйтерсең, йөрәкне телеп,
Яшен ташы кадала.

Җирдә яшәгәч, үз итә
Яңгыры, бозы, җиле.
Хәвеф-хәтәр янап тора,—
Бу бит — адәмнәр иле!

Якты көн кебек каршылыйм,
Барын да кабул итәм.
Җирнең гамен, күк балкышын,
Йөрәктә саклап йөртәм.

## УРАМГА ЧЫККАН МАЛАЙ

Күк йөзенең яктылыгы чагыла,
Күбәләкләр оча тирәмдә.
Каз бәбкәсе кебек, капка астыннан,
Шуып чыкты малай чирәмгә.

Урам читен куе үлән баскан,
Күз алдымда балкый яшеллек.
Кая киткән минем шундый чагым,
Хисләремне булмый яшереп.

Бөтерелә орчык кебек янда,
Иләсләнә бары уенга.
Көн кояшлы, җилләр назлы булсын,
И, ваемсыз малай уенда.

Андый чаклар күптән үткән инде,
Җиргә ятып бик күп аунадым.
Кая миңа хәзер алай йөрү,
Үз хәлемне күптән аңладым.

Кулын сузып, колачларын ача,
Ул өлгерде үзен танытып.
Чирәмлектә бала чагым йөри,
Бар дөньясын йөри онытып...

## КЫЗЛАР ҖЫРЫ

Хозурланды шәфәкъ нуры белән,
Офык чите балкып кызарды.
Болын юлы моңга төрелеп кала,
Кайткан чакта ферма кызлары.

Кызлар шәле кебек эленеп калды,
Агач башларында моң гына.
Сез былбылмы әллә? — җырларыгыз
Күңел кылларына кагыла.

Таң атканда, шәфәкъ батканда да,
Ишетелә кызлар тавышы,
Күзләремне алмый карап торам,
Бер мин генә әллә сагышлы?

Җырыгызны, кызлар, тыңлап калам,
Көннәрегез уза җәйләүдә.
Сөюгәме, әллә сагышкамы —
Бигрәк матур быел җәйләр дә.

## АДӘМ БАЛАСЫН СӨЯЛӘР

Адәм баласын, тугач та,
Ак биләүгә төрәләр.
Иркәләп, назлап сөяләр,
Күз карашын түгәләр.

Халкымның матур йоласы
Килә ерак чорлардан:
Ефәк тасмалар шикелле,
Йөрәкләргә чорналган.

Дөньяга туган баланы,
Йолдызларга тиңлиләр.
Олы өметләр баглыйлар,
Изге теләк телиләр.

Исемне сайлап кушалар,
Бишек җырын җырлыйлар.
Гореф-гадәте буенча,
И, сабыйны зурлыйлар.

Сөя-сөя өшкерәләр,
Икмәге-тозы белән.
Аннан тормыш үзенә ала,
Сагышы-назы белән...

## ҖӘЙ БЕЛӘН КЫШ АЕРЫЛДЫ

Җәй белән кыш аерылган мәлдә,
Күк күкрәп, яшен яшьнәде.
Кичекмәде минутына хәтле,
Табигатьнең бөек эшләре.

Бөреләр дә күзен ачты кинәт,
Яшел ялкын алды кыр өстен.
Зәңгәр яулык болгап сәлам биргән,
Күксел таулар белән күрештем.

Казлар төшкәнмени яланнарга,—
Умырзая ап-ак чәчәктә.
Кабатланып тора ел мизгеле,
Чикләр куя вакыт ничек тә.

Җәй белән кыш, елга яры кебек,
Аерылды тәмам икегә.
Килер көннәр ничек булыр икән,
Нинди уңыш, табыш көтелә.

Җәй кулына күчте барысы да,
Искән җилләр, яуган яңгырлар.
Басуларга игенчеләр чыгар,
Хезмәт җыры илгә яңгырар.

* * *

Яшьләр йөри музей залларында,
Тарихларны кеше өйрәнә.
Әйтерсең лә берни булмаган күк,
Җир үз күчәрендә әйләнә.

Вакыт яңгырлары юып алган,
Гасырлардан калган тузанны.
Таш балталар, сынган ай сөңгеләр
Сөйләп тора күптән узганны.

Музейларга ничек сыеп беткән,
Фиргавеннәр, ханнар мөлкәте.
Ерак чорлар кайтавазы монда:
Бардыр әле башка хикмәте.

Һәрбер ташын аның капшап карыйм,
Дулкынланам үзем бу хискә.
Заман белән, шәхес белән дә мин
Күп вакытта керәм бәхәскә.

Фанатиклар гел табынып яши,
Заман барсын, барсын аралый.
Ул үз геройларын ачыклар бер,
Вакыт хөкеме дә бар әле.

## ТУГАН ЯК

Усаклының үрләренә менсәм,
Туган якка карыйм, күренә.
Каеннары шаулап яфрак ярган,
Аккошлары төшкән күленә.

Җаным тетрәп атылырга тели,
Утны-суны кичеп сикерә.
Битләремнән сөеп җилләр үпте,
Гөлләр сипте юллар читенә.

Туган якның күкрәүләрен тоям,
Яңгыр суларына чылансам.
Сагышларны татыган кеше аңлар,
Күзләремнән яшьләр чыгарсам.

Кабынырга торган усак төсле,
Йөрәк тулы кайнар хисләргә.
Узган юлларыма түгелеп калган
Тальян моңы айлы кичләрдә.

Түбәләрем күккә тияр иде,
Аяк бассам газиз җиремә.
Сагынганда битләремне куям,
Туган якның искән җиленә.

## КҮК ЙӨЗЕ

Зәңгәр төндә, якты иртәләрдә,
Күзләремне тегәм күгеңә.
Күз алдыма ниләр генә килми,
Җәннәт төсле серле күренә.

Олы диңгез кебек серен саклый,
Тирән бушлык ята — күк чиксез.
Күпме галәм анда — күк артында,
Күпме йолдыз анда — билгесез...

Болытларны җил туздырып куя,
Күк читендә күкрәү йотыла.
Яу кырында, соңгы солдат кебек,
Яшен чатнап җиргә атыла.

Олы экран итеп күкне карыйм,
Ят авазлар, яшерен өн килә.
Уйнаш хатынмыни — күзен кыса,
Шаян кызлар кебек көн көлә.

Шәфәкъ бата, нәҗагайлар уйный,
Мәңге алыш, мәңге хәрәкәт.
Кош юлларын иңләп кояш үрли,
Җиргә куна күктән бәрәкәт.

## ПАР КАНАТЫҢ БУЛЫР ИДЕМ

Күл буенда ялгыз аккош калган,
Канатлары аның яралы.
Күктәшләрен ничек эзләп тапсын,
Оча алмый ерак араны...

Мин үзем дә беләм ялгызлыкны,
И кошкаем, аңлыйм хәлеңне.
Уйланасың, моңланасың, беләм,
Сагынасың туган илеңне...

Күк өстеннән уза кош юллары,
Томаннарын җиргә тараткан.
Нинди гамьсез җаннар каһәрләгән,
Канатларың кемнәр канаткан?

Тын сукмаклар безгә уртак икән,—
Ялгызлыкны авыр кичерәм.
Пар канатлар булыр идем сиңа,
Мөмкин булса, килсә көчемнән.

## КЫЗЛАР КҮРСӘМ

Минә хикмәт: чибәр кызлар
Очрап тора каршыма.
Тыныч кына узганым юк,
Күз төшерәм барсына.

Кызларның якты карашы
Карны-бозны эретә.
Күңел зары онытыла,
Бәгыремне терелтә.

Мин, гүя бер кош баласы,—
Талпынам, канатланам.
...Кызлар күрдисәм, сөенәм:
Мин әле яраталам.

## ХАКСЫЗЛЫК БАР

Кешеләрнең төрлесе бар,
Күп изгелек иткәне.
Бил бөксә дә, тир түксә дә,
Юк ашарга икмәге.

Хаксызлыкны күреп яши,
Көн саен, адым саен.
Ничек кенә эш кылса да,
Табалмый тормыш җаен.

Авыр хәлгә юлыкса да,
Яшәргә теләге бар.
Ихтыяр көче җитәрлек,
Ышаныч, терәге бар.

Кая гына юл тотса да,
Җил исә аңа каршы.
Гомер буе теләсә дә,
Кунмаган бәхет кошы.

Адашкан юлаучы сыман,
Юл эзли, тапмый башка.
Өмете акланмый кала,
Кеше гомере кыска,
Теләкләр кала бушка.

* * *

Бармак селкеп янаучылар да бар,
Яшен сымак атып карашын.
Күрдем инде, белдем инде күптән,
Бу дөньяның агын-карасын.

Юлларыма күпләр, киртә булып,
Баш өстендә тотты күсәкне.
Гаделсезләр әдәп саклап тормый,
Кыргыйлыгын гына күрсәтте.

Мин куркак та, бик юаш та түгел,
Тез чүкмәдем, һич тә баш бирмәм.
Сез — шәфкатьсез, явыз ниятлесез,
Мин — күптәнге кеше, күп күргән.

Сез күпләрне тагын көтмәгәндә,
Гаепләрсез, яла ягарсыз.
Йөз яшәргә көче җитәр иде,
Әгәр булса йөрәк ярасыз,
Нигә күсәк тотып торасыз?

## АВЫЛ КИЧЛӘРЕ

Сирень куаклары чәчәк аткан,
Җанга рәхәт авыл кичләре.
Күңел сагышларын юып ала,
Ашкындыра йөрәк хисләре.

Ай калыкты, йолдызлар да, балкып,
Күк өстендә биеп тирбәлде.
Яшел тирәкләрдән аваз салды,
Сандугачның моңлы телләре.

Япа-ялгыз, авыл урамыннан
Ничә тапкыр урыйм төннәрен.
Еракларда аҗаган күк уйный,
Җыр тавышы әллә кемнәрнең.

Картлар тирән йокысына талган,
Татлы булсын күргән төшләре.
Мин дә китәм инде, сау булыгыз,
Авылымның ямьле кичләре.

## ЭЧТӘЛЕК

Рәхмәт, җирем .......... 5
Язмыш уртак .......... 6
Юлаучыга юлдаш булам .......... 7
Вакыт .......... 8
Ир итте .......... 9
Сәхрәләргә чыгам .......... 10
Тол хатын монологы .......... 11
Бөтен байлыгым .......... 12
Оран салам .......... 13
Ятим калган тирәгем .......... 14
Хөсетле кешегә .......... 15
Өч тәрәзәле йортым .......... 16
Җир күрсәтми ярасын .......... 17
Җырлы Казан! .......... 18
Халкым көрәшә .......... 19
Төштә күрәм .......... 20
Сөюдә сыналгансың .......... 21
Кошлар да сине сагына .......... 22
Серләремә, әни, кердең .......... 23
Беренче кар .......... 24
Юксынуым бетми .......... 25
Гармун тавышларын ишетсәм .......... 26
Дус та, юлдаш та син .......... 27
Чуар замана .......... 28
Апрель таңы .......... 29
Күрәсем дә, беләсем дә килә .......... 30
Нинди җилләр исәр .......... 31
Җыр канаты .......... 32

Бүә буйларында йөрим ........ 33
Мине табарсың ........ 34
Елмаеп-көлеп яшим ........ 35
Изгелеген тоям ........ 36
Көзгеләргә карап ........ 37
Тормыш зары бетми ........ 38
Кеше күңеле бушансын ........ 39
Бәрәкәтле җирем ........ 40
Чишмә тавышлары ........ 41
Хәтер китабы ........ 42
Басу юллары ........ 43
Ташу сулар ага ........ 44
...Их, дигәнче бер ел узып ........ 45
Җир яме ........ 46
Чит җирләрдә гомер үтә ........ 47
Карлар күмгән тугайларны ........ 48
Нинди хәлгә калдык? ........ 49
Ялгызлык хисе тоям ........ 50
Карлар ява ........ 51
Киләчәккә карыйм ........ 52
Печән чапкан тугаем ........ 53
Син яшьлек язында ........ 54
Егет булу кирәк ........ 55
Минем күңел ........ 56
Җиңү бәйрәме ........ 57
Узган гомер уйландыра ........ 58
Көткән көнем ........ 59
Горурлык хисен саклыйк ........ 60
Мәхәббәтең барын тойдым ........ 61
Дала ........ 62
Дулкын уят ........ 63
Язлар яме күңелемдә ........ 64
Базар ........ 65
Кар явармы, әллә яңгырмы ........ 66
Хыял канатларым яралы ........ 67
Сүзсез калдык ........ 68

Сиздермәскә телим ................................ 69
Үзгәрә дөньясы ................................ 70
Йөрәк сагышлы ................................ 71
Карашымны төбим ................................ 72
...Хәвеф-хәтәр читләп үтми ................................ 73
Тынлык эзлим ................................ 74
Күзләремдә яшьлек дәрте ................................ 75
Иҗат ялкыны сүнмәсен ................................ 76
Югалтмаек кадерне ................................ 77
Теләгенә кеше ирешә ................................ 78
Бәйрәмнәрне көтеп алам ................................ 79
Ирләрнең төрлесе бар ................................ 80
Болын ................................ 81
Киләчәккә юллар бара ................................ 82
Төрле хәлләр була ................................ 83
Күрешү көнен көтәм ................................ 84
Рәхмәт, язмыш ................................ 85
Кыш мизгеле ................................ 86
Соңгы юлга чыктың ................................ 87
Көннәр йончу быел ................................ 88
...Тәрәзәмә карлы яңгыр ява ................................ 89
Барысын да күрсәтте ................................ 90
Мәҗлестә ................................ 91
Гармуным кулларымда ................................ 92
Чәчкә куям әти каберенә ................................ 93
Яшен ................................ 94
...Мин дә горурлык хисе кичердем ................................ 95
Вакыт хөкеме ................................ 96
Бал кортлары ................................ 97
Язгы җилләр ................................ 98
...Төн артыннан көткән көнем килә ................................ 99
Моңсу чагым ................................ 100
Малай чаклар кайда калды? ................................ 101
Ялгызлык ................................ 102
Җир ................................ 103
...Җир шикелле кинәт тетрәп куям ................................ 104

Төннәр буе чигү чигәсең ........................ 105
Күзге моң ........................................... 106
Вакытым юк ........................................ 107
Болгар җире ........................................ 108
Татар халкы ........................................ 109
Яфраклар да серләшә ........................... 110
Йөрәктә саклыйм .................................. 111
Урамга чыккан малай ............................ 112
Кызлар җыры ....................................... 113
Адәм баласын сөяләр ............................ 114
Җәй белән кыш аерылды ........................ 115
...Яшьләр йөри музей залларында ........... 116
Туган як .............................................. 117
Күк йөзе .............................................. 118
Пар канатың булыр идем ........................ 119
Кызлар күрсәм ..................................... 120
Хаксызлык бар ..................................... 121
...Бармак селкеп янаучылар да бар ......... 122
Авыл кичләре ...................................... 123